2022 год культурного наследия народов России



ГАПОУ «МЕНЗЕЛИНСКИЙ ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ КОЛЛЕДЖ ИМЕНИ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ»

РЕСУРСНЫЙ ЦЕНТР ПО ПОДГОТОВКЕ НАЦИОНАЛЬНЫХ КАДРОВ

# Развитие внутреннего мира ребёнка средствами театрального искусства

***Материалы Регионального семинара-практикума***

***(25 ноября 2022г.)***

***Мензелинск, 2022***

Печатается по решению оргкомитета Регионального семинара-практикума.

Оргкомитет Регионального семинара-практикума:

Р.М. Ибрагимов-директор ГАПОУ «Мензелинский педагогический колледж»;
И.Х. Зайнутдинова - заместитель директора по УМР;
А.Р. Гайниева – заместитель директора по информатизации;
И.М.Галиева –председатель ПЦК русской и татарской филологии;
Л.И.Хуснутдинова – заведующий методическим кабинетом

«Развитие внутреннего мира ребёнка средствами театрального искусства»:

*Материалы Регионального семинара-практикума (25 ноября 2022 г.). Мензелинск.2022,-стр.*

В сборнике представлены материалы Регионального семинара-практикума, приуроченного к Всероссийской неделе «Театр и дети», среди учителей и преподавателей ОО, воспитателей ДОО РТ «Развитие внутреннего мира ребенка средствами театрального искусства». В которых отражен инновационный опыт педагогов: преподавателей ГАПОУ «Мензелинский педагогический колледж имени Мусы Джалиля» и учителей, образовательных организаций, воспитателей ДОО Северо - восточного региона РТ.

Целью Семинара является расширение знаний педагогов о театрализованной деятельности обучающихся и совершенствование практических навыков, необходимых для работы по воспитанию детей в данном направлении.

Материалы рассчитаны на широкий круг участников образовательного процесса.

Материалы печатаются в авторской редакции. Оргкомитет не несет ответственность за содержание и ошибки.

# СОДЕРЖАНИЕ

**СЕКЦИЯ 1 «РАЗВИТИЕ ТВОРЧЕСКОЙ АКТИВНОСТИ ДЕТЕЙ В ТЕАТРАЛИЗОВАННОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ» (ДЛЯ ПЕДАГОГОВ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ НАЧАЛЬНОГО, ОБЩЕГО И ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ)**


1. **Гилязетдинова Гулнур Мирзануровна** Сәхнә тәрбиясе бирүдә “Илһам” иҗат түгәрәгенең роле........................................................................................5
2. **Миршарипова Танзиля Котдусовна.** Опыт работы по развитию творческой активности детей в театрализованной деятельности.......................................................................................10
3. **Назмеева Рамзия Тагировна.** Роль театра в воспитании детей ……………………………………………………………………………14
4. **Ханова Айсылу Илгиз кызы**. Сәхнәләштерү эшчәнлеге аша балаларның сөйләм телен үстерү.........................................................................................18
5. **Хамаева Гульфина Азгаровна** Могҗизалар дөньясы ул – театр.........................................................................................22
6. **Хайруллина Илгиза Муфаздаловна** Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә театральләштерү элементларын куллану.......................................................................................26
7. **Хузина Ильсеяр Дильфасовна**. Развитие творческой активности детей в театрализованной деятельности.......................................................................................29


**СЕКЦИЯ 2 «ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ТЕАТРАЛИЗОВАННОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ В РАЗВИТИИ РЕЧИ ДОШКОЛЬНИКОВ» (ДЛЯ ПЕДАГОГОВ ДОШКОЛЬНЫХ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ)**


1. **Авзалова Илюза Ильфаковна.** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсешендә театр эшчәнлегенең әһәмияте.......................................................................................33
2. **Аглямова Лилия Булатовна .** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм телен устерүдә театр эшчәнлегенең роле...............................37
3. **Галиева Илфания Мусавировна, Талипова Гульназ Фазыловна**. Развитие речи и творческой активности детей посредством театра «Тантамарески» ……………………………………………….39

4. **Закирова Фирюза Ульфатовна**. Балалар бакчасында театр эшчәнлеге……...........................................................................42
5. **Ильина Ольга Николаевна**. Влияние театрализованной деятельности на речевое развитие дошкольников…………………………………………………………46
6. **Краснопёрова Татьяна Алексеевна, Хабирова Фирая Захировна**. Использование элементов театральной деятельности в подготовке воспитателей как будущих специалистов……………………………51
7. **Мортазина Гульчачак Мурдафитовна.** Театрализованная деятельность в обучении детей татарскому языку…………………………………………………………………56
8. **Муллахметова Илюза Мирзаханофовна**. Театрализация как средство повышения мотивации при обучении английскому языку……………………………………………………………………60
9. **Мухаметдинова Ландыш Мухаррамовна.** Балалар бакчасында театр сәнгате аша татар телен өйрәтү……………………………………63
10. **Нуриманова Илюза Флусовна.** “Балаларның сөйләм телен үстерүдә театр сәнгатенең роле”.....................................................................65
11. **Нурутдинова Лилия Рашитовна** Сәхнәләштерелгән уеннар аша балаларда сөйләм культурасы тәрбияләү..........................................69
12. **Салахова Лилия Сириновна.** Развитие речи детей через театрализованную деятельность. ………………………………...73
13. **Хаертдинова Лейсан Радиковна.** Театр эшчәнлеге аша балаларның сөйләм телен үстерү.......................................................................77
14. **Халиуллина Венера Васыловна** Мәктәпкәчә яшьтәге балалар тормышында Театр. .......................................................................80
15. **Халиуллина Нафиса Ирхатовна** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәләтләрен һәм иҗади потенциалын үстерүдә уңай шартлар тудыру..83
16. **Хасанова Найля Назифовна.** Түгәрәк алан әкияте...........................88
17. **Юзыкаева Лилия Борисовна.** В театр играем-речь развиваем.........94

**СЕКЦИЯ 3 «ОРГАНИЗАЦИЯ И РУКОВОДСТВО ТЕАТРАЛИЗОВАННОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬЮ ДЕТЕЙ» (ДЛЯ СТУДЕНТОВ И ПРЕПОДАВАТЕЛЕЙ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ СРЕДНЕГО ПРОФЕССИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ).**

1. **Бубекова Ильмира Азгамовна, Имамутдинова Расима Галиаскаровна** Урман аланында................................................98
2. **Титова Неля Музафаровна.**Чему учит студенческий театр?.....101

# СЕКЦИЯ 1 «РАЗВИТИЕ ТВОРЧЕСКОЙ АКТИВНОСТИ ДЕТЕЙ В ТЕАТРАЛИЗОВАННОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ» (ДЛЯ ПЕДАГОГОВ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ НАЧАЛЬНОГО, ОБЩЕГО И ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ

## Сәхнә тәрбиясе бирүдә “Илһам” иҗат түгәрәгенең роле

**Гыйлаҗетдинова Г.М.**
*Минзәлә шәһәре, Муса Җәлил исемендәге*
*Минзәлә педагогия колледжы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Узган гасырның әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә уңышка ирешкән кайсы гына шәхеснең тәрҗемәи хәленә мөрәҗәгать итмә, һәркайсында “мәктәптә оешкан әдәби түгәрәккә йөри, беренче әсәрләре мәктәп стенгазетасы, район газетасы битләрендә басыла, мәктәп сәхнәсендә беренче адымнарын ясый” дигән юлларны укырга мөмкин. Димәк, дәрестән тыш оештырыла торган уку формасының бер төре булган әдәби түгәрәкләрнең төп максаты балаларны төрле яклап иҗат эшенә тарту булган. Узган гасырның 90 нчы елларында җәмгыятьтә барган үзгәрешләр түгәрәкләрнең эшчәнлегенә дә шактый зур зыян салды. Шулай да күп кенә уку йортлары бу традицияләрне югалтмаска тырыштылар, киресенчә, аны саклап кына калмыйча, заман мөмкинлекләреннән файдаланып, тагы да үстерергә тырыштылар. Мин сезне Минзәлә педагогия училищесында/колледжында 30 ел дәвамында әле кайнап, әле сүрелебрәк, ләкин даими эшләп килүче “Илһам” иҗат түгәрәгенең эшчәнлеге белән таныштырып китәргә телим. Ни өчен кайнап-сүрелеп эшләвенә хәзер үк аңлатма биреп китим. Түгәрәк ул – теге яки бу өлкә белән кызыксынучылар оешмасы. Менә безнең түгәрәкнең эшчәнлегенә дә шул йогынты ясый. 30 еллык яшәү дәверендә аның эше 3 юнәлешнең тибрәнешен чагылдыра

Минзәлә педагогия училищесында 1992 нче елда иҗади сәләткә ия булган бер төркем студентлар әдәби түгәрәккә оешалар, аңа “Илһам” дип

исем бирәләр. Биредә кызлар-егетләр шигырь язу серләре белән танышалар, үзләренең әсәрләрен укыйлар, үзара тәнкыйтьлиләр, бер-берсенә киңәшләр бирәләр. Аларның иҗат җимешләрен иптәшләренә күрсәтү максатыннан, ел саен Г. Тукай туган көндә “Яшь талантлар” кичәсе үткәрү матур традициягә әверелә. Соңрак бу кичәләрнең эчтәлеге тагы да киңәя, анда студентлар белән бергә Минзәлә төбәгеннән чыккан язучылар, шагыйрьләр дә чыгыш ясый башлый. Беренче шундый кичәгә С. Гәрәева белән Р. Гәрәйләр чакырыла. Соңрак “Җомга көн кич белән” дип аталган бу шигырь бәйрәмнәренә Актаныштан М. Мирза, элекке Минзәлә педучилищесы студенты, хәзерге вакытта Сарманда яшәп иҗат итүче В. Хәйруллина һәм җирле шагыйребез мәрхүм Азат Мәрдән кунак итеп чакырыла. Алар белән очрашу вакытында каләм тибрәтүче яшьләр үзләренең әсәрләрен укыйлар, өлкәннәрнең хәер-фатыйхаларын алалар. Шулардан бүгенге көндә татар әдәбиятының күренекле вәкиле, танылган шагыйрь Ленар Шәехне аерып атап үтәсе килә.

“Илһам”лылар үзләренең әсәрләрен “Минзәлә” газетасы, “Идел” журналы, КДУда чыгып килгән “Тәрәзә” исемле студентлар газетасы битләрендә бастырып чыгардылар, төрле конкурсларда катнаштылар. 2008 нче елда, мәсәлән, КДУ оештырган “Шигъри Сабантуй” региональ фестивалендә катнашып, Равилов Нияз һәм Хәйбрахманова Радмила Диплом белән, ә түгәрәк “Идел” журналына еллык подписка белән бүләкләнделәр. 2013, 2015 нче елларда үткәрелгә бәйгеләрдә катнашып, Гыйлаҗетдинова Гөлшат Диплом иясе булды.

2007 нче елда түгәрәкнең икенче юнәлеше барлыкка килде: без студентлар көче белән үз газетабызны – “Яшьтәш”не чыгара башладык. Рубрикалар төрлелеге, басылган мәкаләләрнең эчтәлеге тиз арада газетаның укыла торган басма булуына китерде. Мәгълүмати технологияләрнең үсүе укучыларның географиясен дә киңәйтте, инде аны сайтка кереп, ата-аналар

да, таныш-белешләр дә укый һәм бәяли башладылар. Шушы газетаны чыгаруда башлап йөргән студентларыбыз Дифиза Нуриева бүгенге көндә “Минзәлә” газетасы редакциясендә эшли.

2009 нчы елдан башлап, түгәрәкнең яңа юнәлеше – “Студент сәхнәсе” эшли башлады. Түгәрәкнең максаты: студентларны әдәби телдә матур сөйли, сәхнәдә үз-үзләрен тота белергә өйрәтү; сүзнең матурлыгын, туган телнең кеше тормышындагы алыштыргысыз ролен студентның аңына сеңдерү.

Түгәрәкнең бурычлары:

- студентларны иҗади дәртләндерү, аларда иҗат итүгә теләк уяту;

-төрле конкурсларда катнашу, укучыларның буш вакытларын файдалы итеп үткәрүгә ирешү.

“Илһам” иҗат түгәрәгенең программасы түбәндәге этаплардан тора:

1. Оештыру эшләре. Укучыларны түгәрәккә туплау, максат һәм бурычлар, планнар белән таныштыру, инструктажлар үткәрү, үткән уку елында эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау.
2. Сәхнә серләре. Әсәр белән танышу. Образларның үзенчәлекләрен билгеләү. Уйналырга тиешле образның башка образлар белән бәйләнеше. Костюмнар әзерләү. Декорацияләр әзерләү. Музыкаль бизәлеш.
3. Әсәрне куярга әзерләү. Текстны өйрәнү: рольләргә бүлеп уку, парлап әзерләү, күренешләп әзерләү. Сәхнәдә репетиция ясау.
4. Әзерләнгән әсәрләрне сәхнәгә кую. Һәр уку елында нинди дә булса зур күләмле сәхнә әсәрен яки теге яки бу юбилярның әсәрләреннән өзекләрне әзерләү һәм сәхнәгә кую.
5. Еллык эшләргә нәтиҗә ясау. Апрель аенда Тукай атналыгы уңае белән үткәрелә торган "Илһам” иҗат түгәрәгенең ачык утырышында

я Г. Тукай әсәрләре буенча куелган кече күләмле сценкалар, яисә шаян скетчлар бәйләме белән чыгыш ясау.

Студентлар көче белән Рабит Батулланың “Кичер мине, әнкәй”, Т. Миңнуллинның “Кәрлә мәктәпкә бара”, Юныс Әминовның “Өти балак” әсәрләре сәхнәгә куелды. Ә Туфан Миңнуллинның “Ак тәүбә, кара тәүбә” әсәре 2 тапкыр тамашачы студентлар игътибарына тәкъдим ителде.

Уңышларыбыз да бар. Т. Миңнуллинның скетчларыннан төзелгән тамаша белән студентларның “Сәхнә” театры 2009нчы елда II дәрәҗә дипломга лаек булды. Төрле елларда “Американ”, “Өти балак” әсәрләре буенча куелган өзекләр номинациядә җиңүчеләр булсалар, халыкара Җәлил укулары өчен тәкьдим ителгән “Яшь ана” композициясе – зонада 3 нче урынга, “Истә” композициясе 2020 нче елда финалда 3 нче урынга лаек булдылар. Ә 2019 нчы елда С. Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры оештырган фестивальдә укытучылар һәм студентлар катнашында куелган Р. Батулланың “Кичер мине, әнкәй” спектакле 1 нче дәрәҗә Диплом белән бүләкләнде. 2022 нче елда Г. Рәхимнең “А-ля шер туны” скетчы белән Казанда уздырылган “Студент язы” фестивалендә катнаштык.

Билгеле, түгәрәкнең эшләре болар белән генә чикләнми. Төрле дәрәҗәләр уздырыла торган бәйгеләрдә катнашу өчен, планнан тыш эшләр белән шөгыльләнергә туры килә. Колледжда уздырыла торган чараларда, район мәдәният йортында төрле бәйрәм уңаеннан куела торган концертларда да даими катнашабыз. Сәхнәдә йөрергә өйрәнгән студентлар белән бергә рольләргә түгәрәккә йөрмәгән кызларны-егетләрне дә тартырга туры килә. Тора-бара алар да бу эштә үзләре теләп катнаша башлыйлар.

Уңышларга ирешүебездә, билгеле, студентлар энтузиазмы, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының театр сәнгатен яратулары белән бергә төрле

елларда С. Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры режиссеры Д. Сәмерханов, артистлары Р. Муллина, Р. Әхмәтҗановлар белән хезмәттәшлекнең нәтиҗәле булуын да әйтмичә китеп булмый. Моннан тыш, түгәрәк әгъзалары белән Минзәлә театры сәхнәсендә уйналган тамашаларны даими карау, аларны анализлауның да студентларның сәхнә культурасын үстерүдә, үз-үзләрен сәхнәдә ышанычлы тотуларына ирешүдә, уйнаячак образларын күзаллауларын формалаштыруда роле зур. Түгәрәккә йөреп, төрле тамашаларда катнашып, үзләрен күрсәткән егетләребез Гозәеров Данилны, Мухамаев Алмазны, Вәлиуллин Ренатны Тауасты Байлар халык театры куйган спектакльләрдә катнашырга чакырдылар. Димәк, колледж бу егетләрнең сәләтен ачуда үзеннән өлеш керткән дип әйтергә мөмкин.

Йомгак ясап, шуны әйтәсе килә: дәрестән тыш эшләр, шул исәптән түгәрәкләр, нинди генә максатны алга куйсалар да, кайсы гына фән белән бәйле булсалар да теге яки бу ахыргы нәтиҗәгә ирешергә тиешләр. Студент ул – иртәгәге көннең укытучысы, тәрбиячесе. Иҗат түгәрәгенә йөреп чыныгу алган һәр яшь белгеч киләчәкнең иҗатчысын эзләп табучы, аның сәләтен вакытында күреп алып үстерүче булырга тиеш. Шулай булганда, милләтебезнең иҗат чишмәсе саекмас, мдәнияте үсүдән туктамас.

## Опыт работы по развитию творческой активности детей в театрализованной деятельности.

***Миршарипова Танзиля Котдусовна,***

*учитель английского языка,*

*МБОУ «Актанышская СОШ №2 с углубленным*

*отдельных предметов» Актанышского района РТ*

Цель: обучение участников мастер – класса использованию элементов творческой активности в театрализованной деятельности

Задачи:

- Повысить уровень психолого-педагогической компетентности педагогов.
- Познакомить участников мастер-класса с методами и приемами.
- Проявить творческие способности на протяжении всего мастер класса.

Свой мастер класс начну я со слов знаменитого татарского писателя Габдуллы Тукая из стихотворения «Театр»

Театр — и зрелище и школа для народа,
Будить сердца людей — вот в чем его природа!

Любое искусство, и театр в том числе, занимается одним — делает из человека человека. Сейчас люди, а сегодня поговорим о детях, привыкли смотреть 40-секундные ролики на YouTube, в инстаграммах и в Тик Токе, а тут спектакль идёт полтора часа. С одной стороны, дети меняются, но с другой, остаются детьми. Несмотря на обилие гаджетов, у ребёнка всё равно есть любимый зайчик, мишка или машинка.

Нам учителям предстоит увлечь их, заинтересовать, чтоб достигнуть нашей цели. Главная цель педагогической деятельности в современных условиях – формирование разносторонне развитой личности, которая будет способна реализовывать творческий потенциал в динамичных социально-

экономических условиях, как в собственных жизненных интересах, так и общественных, государственных.

Мы начинаем с «Круга радости». Это создаёт благоприятный эмоциональный настрой на весь день. Сейчас я хочу показать вам одно из таких упражнений: «Улыбка» (Играть можно парами или стоя в круге). Что вы почувствовали, ощутили? (Ответы педагогов).

Ребёнок развивается как личность, когда осваивает взрослый мир доступным ему образом — в игре. Поэтому дети играют в дочки-матери, в профессии, поэтому повторяют в игре ситуации, увиденные или прожитые в реальной жизни. Игра позволяет взглянуть на мир с разных сторон, из разных ролей, примерить на себя и свое формирующееся мироощущение те или иные стороны конфликта или отношений. (игра с картинками разных профессий)

Играя, ребёнок формирует основы своего мировоззрения, определяется как член социума. Театр позволяет проживать роли «почти по-настоящему».

Дети на спектаклях реагируют на происходящее на сцене очень эмоционально, искренне. Они стремятся предупредить положительных героев об обмане или опасности, переживают, когда герой попадает в беду, ликуют, когда все заканчивается хорошо. В этот момент и происходит кристаллизация базовых этических понятий.

Еще более яркими становятся впечатления ребёнка, если он сам принимает участие в игре. (озвучка мультика, например, или игра с карточками, выбирают каждый 1 карточку и фантазируют, можно придумать сказку спонтанно или ваши фантазии.)

Детям играть легко. Игра для ребёнка — естественное состояние, не требующее напряжения, не знающее комплексов. Играя, дети раскрываются, творчески и эмоционально развиваются, совершенствуют коммуникативные навыки. Например, для коммуникации есть игра БИНГО, то же самое что и лото.

Дети, занимающиеся в театральных кружках, более дисциплинированны и ответственны. По сравнению с ровесниками у них лучше развита логика и речь, они более связно и образно мыслят, легко находят общий язык с людьми, более открыты для общения и обучения, отличаются целеустремленностью и инициативностью. Часто все это оказывается связано и с более высокой успеваемостью в школе, а в дальнейшем — и с успешным карьерным ростом.

Несомненно, каждого ребёнка нужно приобщать к культуре и искусству!

Наше время – это время перемен. Сейчас России нужны люди, умеющие творчески мыслить, способные принимать нестандартные решения. Только человек, с хорошо развитой фантазией, даже с недостатком знаний и опыта, относительно уверенно чувствует себя в сложном и изменчивом мире. Представьте на минуту, что человек не обладал бы фантазией, мы лишились бы почти всех научных открытий и произведений искусства. Дети не услышали бы сказок и не смогли бы играть во многие игры. А как они смогли бы усваивать школьную программу без воображения? Проще сказать – лишите человека фантазии и прогресс остановится! Значит, воображение и фантазия являются высшей и необходимейшей способностью человека.

Закончу свое выступление словами Тукая

И если ты хорош — то только лучше станешь,
А если ты дикарь — из темноты воспрянешь.
В театре рангов нет, в нем так заведено:
Ты господин иль раб — театру все равно!

**Список литературы:**

1. Антипина Е.А. Театрализованная деятельность в детском саду.-М., 2003

2.Павленко, С. В. Развитие творческих способностей у детей средствами театрализованной деятельности / С. В. Павленко. — Текст: непосредственный // Молодой ученый. — 2019. — № 37 (275). — С. 155-156.

# Роль театра в воспитании детей

**Назмеева Рамзия Тагировна,**
*учитель начальных классов,*
*Муниципальное бюджетное*
*общеобразовательное учреждение*
*«Средняя общеобразовательная школа №3»*

Театр – это живое общение, однако в настоящее время в нашу жизнь все более прочно входят новые информационные технологии. Интернет, поглощая ребёнка, вытесняет развитие речи ребёнка. Речь у большинства школьников страдает многими недостатками. Театральная деятельность является эффективным средством в развитии коммуникабельности у младших школьников, а также развивает мышление, внимание, умственные способности, память, происходит коррекция поведения, что необходимо детям в дальнейшем обучении.

Особое значение театральное творчество приобретает в начальной школе. Оно не только помогает воспитывать, но и обучает с помощью игры, т.к. для детей игра в этом возрасте – основной вид деятельности, постоянно перерастающий в обучение.

Начиная с первого класса, ученики привлекаются в театральную деятельность. Исключительно во всех уроках можно применять элементы театрализации. В своей работе стараюсь обеспечить полноценное усвоение учащимися школьной программы и развитие их познавательных возможностей, не допуская при этом перегрузки. Помогает в этом театрализация. На уроках создаются условия, соблюдение которых способствует формированию, развитию и укреплению познавательного интереса младших школьников.

Основными формами работы можно считать:

- ✓ игровые упражнения на уроках чтения, окружающего мира, изобразительного искусства, где дети исполняют роли животных;
- ✓ подвижные игры с распределением ролей («Гуси-лебеди», «Два Мороза», «Бездомный заяц» и т.д.);
- ✓ дыхательная и голосовая гимнастики;
- ✓ воображаемые путешествия
- ✓ театрализованные игры;
- ✓ проведение спектаклей.

Данные виды работ требуют от ученика творческого подхода, у него расширяется кругозор, развивается речь. В моей практике были случаи, что у ребёнка исчезали дефекты речи. Результат творческой деятельности — не

только дальнейшее совершенствование полученных знаний, но и всемерная активизация мышления учащихся, развитие их познавательных способностей.

Дети младшего школьного возраста ещё раскрепощенные, не стесняются играть, подражать героям сказок, придумывать занимательные истории. Следовательно, они с огромным желанием участвуют во внеклассных мероприятиях. Ученики являлись победителями в конкурсе чтецов, участвовали и побеждали на школьных, городских конкурсах, таких, как Межрегиональный чемпионат BabySkills среди учащихся, Национальный фестиваль народного творчества «Без бергэ» номинация «Художественное чтение сказки», Региональный семинар «За строкой летит строка», посвященный 116-летию со дня рождения татарского поэта – героя Мусы Джалиля, конкурс стихов «День неизвестного солдата», Региональный конкурс проектных работ «Грани творчества», и т.д.




Национальный фестиваль «Без бергэ». Лауреат 1 степени Газеев Радмир, Дипломанты 1,2 степеней Миннахметов Ислам и Фазлиддинзода Озарахш.






Региональный семинар «За строкой летит строка», посвященный 116-летию со дня рождения татарского поэта – героя Мусы Джалиля. Петрова Анна, Сахапова Ясмина - диплом 3 степени, Семёнова Кира - номинация «За самое лирическое исполнение», Габделхаков Ранель - «За артистичность».

Театральная постановка - «продукт» совместной деятельности, который требует концентрации сил каждого учащегося. Появляется прекрасная возможность для учителя – привлечение родителей в воспитательный процесс. Подготовить выступления силами детей и родителей делает работу результативной. Родители помогают учить роли, готовить костюмы и сами участвуют в представлении. Задачей становится привлечь интересы младших школьников и их родителей к театральному действу, показать им интереснейшие возможности реализации фантазии, увлекательность игры на сцене или наблюдения за ней из зрительного зала. И показать перспективы роста ребёнка как личности.

В результате использования элементов театрализации можно выделить, что у большинства учащихся:

- ✓ улучшились показатели успеваемости, дети стали более дисциплинированные, собранные;
- ✓ исчезли страх и скованность, дети стали активными, инициативными;
- ✓ исчезла агрессивность в индивидуальном поведении и общении;
- ✓ появилось желание выполнять различные упражнения коллективно, но не для того, чтобы иметь возможность спрятаться за чужими спинами, а чтобы чувствовать и самому оказывать поддержку партнеру;
- ✓ появилось чувство коллективизма, доброжелательность;
- ✓ у многих детей обнаружились и развились творческие способности: художественные, музыкальные, поэтические, многие сочиняют стихи, сказки.

Иными словами, результаты показывают, что у многих детей их способности стали перерастать в творческие потребности.

Недаром говорят, что каждый ребенок талантлив. Нужно только раскрыть его талант. Театрализация как раз и помогает развить талант каждого, что позволит ребенку найти себя и свой путь в жизни.

**Список источников литературы**

1. Выготский, Л.С. Игра и ее роль в психическом развитии ребенка: Вопросы психологии. – 2005. – № 6. – С.65 – 69.

2. Догадина, Н.В. Театральная деятельность в начальной школе. [Электронный ресурс], 2020. Режим доступа к статье: https://infourok.ru/statya-s-prezentaciej-teatralnaya-deyatelnost-v-nachalnoj-shkole-iz-opyta-raboty-4425358.html ,
3. Садовникова, Т.Е. Театрализация, как средство развития личности ребёнка. [Электронный ресурс], 2019. Режим доступа к статье: https://school-science.ru/11/10/46349

# Сәхнәләштерү эшчәнлеге аша балаларның сөйләм телен үстерү

**Ханова Айсылу Илгиз кызы,**
*Минзәлә шәһәре, 2 нче урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Ел саен башлангыч мәктәпкә яңа балалар килә. Аларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә,сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Баланың бөтен тормышы уен. Уенда бала тирә-юнь турында, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, ә бу дөньяда яшәргә, үзенең мөгамәләләрен төзергә өйрәнә. Ә бу баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес, матур, әйбәт сөйләшә белүен таләп итә. Сәхнәләштерү уеннарында катнашып, балалар образлар, төсләр, авазлар аша тирә- юнь белән танышалар, ә сораулар балаларны уйларга, анализларга, йомгаклау ясарга мәҗбүр итә.

Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсеше нык бәйләнгән. Персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләгәндә, баланың сүз байлыгы арта, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләнә. Башкарылачак роль баланы чиста, аңлашылырлык итеп сөйләвен таләп итә. Сәхнәләштерелгән уеннар барышында, бала персонажлар өчен кайгырта, үзен алар урынына куя, булышу ысулларын таба, яхшылык һәм явызлыкка үзенең карашын күрсәтә. Баланы төрле яктан үстерә.

Сәхнәләштерү эшчәнлеген алып барганда, һәр бала үзенең кичерешләрен, тойгыларын, теләкләрен, карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел, ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык шартлар тудырырга һәм яшьтән үк өйрәтергә кирәк. Еш кына без киң белемле, сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен, чит кешеләр алдында югалып калуларын

күзәтәбез. Сәхнәләштерелгән уеннар балаларны шатландыралар. Спектакльләрдә катнашып, балалар тирә-юнь белән, төсләр, авазлар белән танышалар, ә уйланылып куелган сораулар балаларны анализларга, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, сизелмичә баланың сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша - яңа сүзләр белән баетыла. Әкиятне укып бетергәч, балаларга нинди дә булса җөмләне тәмамларга, кабатларга, эчтәлеген сөйләргә тәкъдим ителә. Аннан кечкенә хикәяләр алына. Әкренләп монологик сойләм генә түгел, ә диалогик сөйләм дә үсә. Аваз культурасы өстендә эшләнелә. Бала күп нәрсәне исендә калдыра. Аның хәтере үсә. Рольне уйный- уйный, бала әкият дөньясына кереп китә, татар телен истә калдыру җиңеләя. Сәхнәләштерү эшчәнлеге күрсәтүенчә, бала ялгышырга мөмкин, ә менә әкият герое ялгышырга тиеш түгел. Шуңа күрә балалар әкият уйнаганда, сүзләрен 2–3 мәртәбә тырышыбрак өйрәнәләр. Аларның бу шөгыльләрдән соң хәтерләре яхшыра. Яраткан геройлар балаларга үрнәк булалар.Сәхнәләштерү эшчәнлеге балаларга проблемалы ситуацияләрне чишәргә булыша- персонаж аркылы оялчанлыкны, кыюсызлыкны бетерергә, сәнгатьле итеп сөйләргә булыша. Рольне уйнау, баланы башка персонаж алдында чиста, аңлашылырлык итеп аңлатуны таләп итә. Театр бала өчен яп-якты истәлек булып кала.

Ә менә укытучы үзе сәнгатьле итеп сөйләү генә түгел, күрә, ишетә белергә, актерлык, режиссерлык осталыгына да әзер булырга тиеш. Тик ул үзенең актерлык осталыгы белән оялчан баланың уйнау теләген бетереп, караучыга әйләндерергә тиеш түгел. Балалар ялгышудан куркырга, гел караучы гына яки гел катнашучы гына булырга тиеш түгел.

Рольләргә бүлгәндә төрле алымнар кулланыла:

- баланың теләге буенча роль сайлау;
- төп рольләргә оялчан балаларны билгеләү;

- карточкалар буенча рольләргә бүлү;
- парлап уйнау.

Монда ике проблема килеп чыгарга мөмкин:

- һәр балага рольләр житмәсә нишләргә;
- тискәре рольләрне кем уйнар

Беренче проблеманы балаларны төркемнәргә бүлеп чишеп була. Ә икенчесен аңлатырга: әкияттә, сәхнәдә барысы да артистлар. Ә артист уңай рольне дә, тискәре рольне дә уйный белергә тиеш. Тискәре рольне уйнау күпкә катлаулырак та, һәр бала тискәре рольне дә, уңай рольне дә уйный белергә тиеш.

1 нче сыйныфлар белән эшләгәндә, мин аларның матур кастюмнарга, әкият геройларына, битлекләргә кызыкканнарына игътибар иттем. Кием алмаштырып үзгәрү алар өчен бик күңелле күренеш. Әкренләп мин аларда сәхнәләштерелгән уеннарга кызыксыну уята, эчтәлеге зур булмаган курчак театрлары күрсәтә башладым. Башта бу уен охшату кебек уздырылды. Мәсәлән, кешеләрнең, хайваннарның аерым гамәлләрен охшатып кабатларга тырышу. (Чыпчыклар канат кагалар, куян төлкене күреп агач астына сикерде яки батыр әтәч юл буйлап атлый). Тора- бара, балаларны спектакльдәге аерым фразаларны кабатларга теләк уяттым. Балаларны курчак театрының төрле төрләре белән таныштырып, аларны кечкенә- кечкенә шигырьләр, әкиятләр өйрәнү процессына этәрдем. Әкренләп балаларда актив сөйләм, уен осталыклары барлыкка килде.(мимика, ишарә, төрле көчтәге тавыш куллана башладылар) Акрынлап, алар уен аралашу процессына күмелделәр.

Үскән саен, балалар сәхнәләштерү уеннарына кызыкынулары артты.Зурлар төркемендә минем алдыма уен-драматизаөияләрне үзләштерергә ярдәм итү бурычы басты. Монда катлаулы эчтәлек, оригиналь тел чаралары белән сөйләшүче кызыклы геройлар бар.

Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшырды, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары артты, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туды. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсте.

Мин киләчәктә дә сөйләм телен үстерүдә, сәхнәләштерү эшчәнлеге өстендә эшләрмен дип уйлыйм.

# Могҗизалар дөньясы ул – театр

**Хамаева Гөлфинә Әзһәр кызы.** –
*югары категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Минзәлә шәһәренең "2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе"*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

Театр ул - искиткеч могҗиза. Театр ул - һәрвакыт табышмак, көтелмәгән хәлләр, могҗизалар.

Театр – кешеләрне тормыш турында уйлану, үз-үзләренә эчтән карау өчен үз тирәсенә җыя торган тылсымлы учакка тиң ул. Театр турында шулкадәр күп язылган ки, безгә аны өр-яңадан ачу, мөгаен, мөмкин булмастай эштер. Хәтта борынгы греклар да, шәһәр төзергә керешер алдыннан, башта театрның кайда булачагын уйлаганнар. Юкка гына түгелдер. Кайсы гына шәһәргә килсәң дә, анда театр булмаса, шәһәрнең үз йөзе юктыр кебек тоела. Рухи дәрәҗә барыбер театр, сәнгать һәм мәдәниятнең торышы белән билгеләнә.

Татарстан Республикасында якынча 18 театр исәпләнә. “Марсель Сәлимҗанов исемендәге Актерлар йорты” бар.  Район үзәкләрендә, авылларда үзешчән театрлар оештырыла.

**Татарстан театрлары**: А. В. Баталов исемендәге Бөгелмә дәүләт рус драма театры, Әлмәт татар дәүләт драма театры, Болактагы яшьләр театры, Буа дәүләт драма театры, В. И. Качалов исемендәге Казан рус Зур драма театры, Габдулла Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театры, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры,  Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры, «Мастеровые» рус драма театры, Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә дәүләт драма театры,  Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама дәүләт татар драма театры, Аяз Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы

дәүләт татар драма театры, Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры, Казан дәүләт яшь тамашачылар театры, Татар дәүләт курчак театры, Яр Чаллы дәүләт курчак театры.

Ә Казанда барлыгы  9 театр исәпләнә, аларның өчесе -  академик театр.

**Татар театрының күренекле эшлекләре:** Габдулла Кариев, Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, Риза Ишморат,  Салих Сәйдәшев, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Таҗи Гыйззәт, Фатыйма Ильская, Фуат Халитов, Хәй Вахит һ.б.

**Татарстанның театр сәнгате өлкәсендә бирелә торган дәүләт бүләкләре:** Дамир Сираҗиев премиясе, Марсель Сәлимҗанов премиясе «Тантана» премиясе.

Әлбәттә, театр үсешенә, аның шундый тарихка ия булуына вакытлар кирәк булган. Актерлар әзерләү өчен,  махсус уку йортлары ачылган, аларда театрга, әсәрләрне сәхнәләштерүгә кагылышлы фәннәргә нигез салынган.

Мәсәлән, “Актерлык осталыгы”, “Ораторлык сәнгате”, “Сәхнә теле”, “Вокал”, “Бию”, “Сәхнә хәрәкәте”, “Ритмика” һ.б. Бу дәресләрдә булачак актерлар белән киеренкелектән арыну өчен күнегүләр башкаралар, эмоцияләр треннингы үткәрәләр, сәхнә сөйләме, сәхнә хәрәкәтенә, тавыш белән эшләргә,  психофизик зажимнардан, эмоциональ киеренкелектән арынырга, үзеңне ышанычлы тотарга өйрәтәләр.

Әлбәттә, бу предметлар, бу күнегүләр татар теле һәм әдәбияты белән дә бәйләнешле, күпмедер дәрәҗәдә татар теле укытучыларына да кагыла. Безнең дәресләр алар өчен нигез булып тора. Хәзер “театр җиле” мәктәпләргә дә кагылды.  Укучыларны да нәрсәгәдер өйрәтергә тиешбез. Һәм түбәндә без кайбер алымнарга тукталырбыз.

1) Сәхнә хәрәкәтенә өйрәтү өчен, түбәндәге биремнәрне башкарырга була:

**Бирем**. Төрлечә басабыз. Күз алдыгызга китерегез. Сез паркта йөрисез. Яңгыр ява. Кар ява. Аяк устында утлы күмер. Умыртка баганаларыгыз еланга әйләнгән. Юл өстендә бүрәнә ята. Җир тетри. 8 баллы. 1 балл. Әкрен генә урыннарга басабыз. Әле һаман җир тетри. 1 балл. *(Укучылар һәр хәрәкәтне күрсәтәләр)*

2) Спектакль барышында актерлар йөгерү хәрәкәтләре ясыйлар. Җырлыйлар да, бииләр дә. Һәм шул арада, хәлләре беткән килеш, тиз генә сүз әйтергә кирәк була. Менә шул вакытта тын алуны көйләр өчен, төрле авазларны бергә әйтәләр.

**Бирем.** Бергә: ФФ- С-ШШШ. ФФ- С-ШШШ.

3)Спектакль алдыннан актерлар үзләренең мускулларын нормаль хәлгә китерәләр. Бу күнегү "Тәнне үз тонусына китерү" ("Мышечные зажимы").

**Бирем.** Әйдәгез, уңайлы итеп утырабыз. Җайлы итеп кенә аякларны берсе өстенә берсен куябыз. Һәм аяк башы белән һавада төрле хәрефләр ясыйбыз: ә ү ң а д . Аякларны алыштырабыз: т е а т р.

4) Сөйләм аппараты органнарын "уяту "өчен, артикулияцион гимнастика ясау.

**Бирем.** Дөрес итеп утырабыз, көзгеләргә карыйбыз. Бу төр гимнастикада телләр, иреннәр актив хәрәкәттә булалар. Без бүген иреннәр белән эшләрбез.

***А) "Су үгезе"*** (Бегемот)

Авызны тыныч кына зур итеп ачарга һәм ябарга. Күнегүне 4-5 тапкыр кабатлыйбыз. Балага хәл алырга һәм ял итәргә вакыт бирәбез. Авыз сыекчасын йотарга тәкъдим итәбез. Күнегүне 3-4 тапкыр кабатлыйбыз.

***Ә) "Иреннәрдән насос ясыйбыз",*** ягъни алга очландырабыз.

**Б)** ***Иреннәр ярдәмендә авазлар ясау:*** мммм – мо –мо-мо –ми-ми-ми-ббб – бо-бо-бо- ффф...

**Г)** ***Орфоэпик күнегүләр*****: - ж, җә, җи, җү, җиләк, чиләк, җыя.**

**Д)** ***Тизәйткечләр әйтү.***

5) Характерны күрсәтү өчен кулланылучы алымнар: *мимика, җест, пантомима* (хисләрне, фикерләрне хәрәкәт, мимика һәм жест – ишарә белән күрсәтү).

**Бирем.** “Күз алдыгызга китерегез”. *(Укучылар кабатлап баралар)*

- Сезнең кулда алма. Зуур алма. Сез авызыгызны зур итеп ачасыз, тешләп аласыз. Фуу. Ул ачы. Сез икенче алманы аласыз. Тешлисез. Ой, монысы да ачы. Сез өченче алманы аласыз. Ә бу баллы.

фикерләрне хәрәкәт,мимика һәм жест – ишарә белән күрсәтү)

6) “Тере предметлар”.

**Бирем:** үз фантазиягезне җигеп, утүк, будильник, кер юу машинасы, чәйникне җанландырып күрсәтергә.

7) Спектакль барышында актерлар сүзләрен онытырга, я бутап башка сүз әйтергә мөмкиннәр. Менә шул вакытта югалып калмас өчен нишләргә? Бу очракта тиз генә, уйланып тормыйча, сорауларга җавап бирәләр.

8) Парларда эшләү. Театрда актерлар парларда эшли белергә тиешләр.

**Бирем:** “Көзгеле” уены. Кара –каршы басабыз. Берегез көзге, ди. Берегез уң кулын күтәрә, икенчегез сул кулын. (Көзгедә шулай күренә)

Әлбәттә, бу биремнәр, күнегүләр мәктәп укучылары өчен тәкъдим ителә. Театр сәхнәсенә беренче адымнар мәктәптән башлана. Сәхнә – зур, тирән дөнья ул. Беренче адымнарын гына атлаучы яшьләр өчен ул әле серле дә булып тоеладыр, чөнки бер яктан ул театр, сәнгатькә омтылганнарны техника алымнары белән тавыш, сулыш, дикцияләрен профессиональлек юлында тәрбияләсә, икенче яктан әдәбият, мәдәният дөньясына алып керә.

# Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә театральләштерү элементларын куллану

**Хәйруллина Илгизә Муфаздал кызы,**
“*Муса Җәлил исемендәге*
*Минзәлә педагогия колледжының*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*"

Конституция нигезендә Татарстанда ике тел - татар һәм рус телләре – дәүләт телләре булып санала. Республикабызда барлык милләт халыклары да татар телен өйрәнә. Әлеге эш балалар бакчасыннан ук башлана, мәктәпләрдә, урта һәм югары уку йортларында дәвам итә.

Хәзерге вакытта безнең тормышка яңа мәгълүмати технологияләр үтеп керде. Компьютер, Интернет челтәре, телефон, планшет.... болар барысы да балаларны “йотып” алды, аларның турыдан-туры аралашуларын кысрыклады. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә без башка милләттән булган, шулар арасында татар милләтеннән булып та туган телләрен белмәгән балалар белән әлеге телне үзләштерергә тырышабыз. Дәресләр уку, язу, ишетеп аңлау, диалог, монологлар төзү, сөйләү, күнегүләр эшләүгә корылган. Болардан тыш без дәресләрдә театральләштерү элементларын да еш кулланабыз.

Тел дәресләрендә театральләштерү элементларын куллану уку эшчәнлеген уен, сәнгать образлары аша материалны үзләштерүгә юнәлтелгән иҗади процесска әйләндерергә ярдәм итә. Театр педагогикасы элементлары уку процессын төрләндереп кенә калмый, дәрестә иҗади психологик климат тудырып, аны баета. Телне үзләштерүдә күпсанлы кыенлыклар (сүзлек запасы җитмәү, сүзләрнең әйтелеше, грамматика, ә алар җөмлә төзүдә иң әһәмиятлесе, һ.б.) аны үзләштерү процессына кызыксынуны югалтуга китерә. Дәресләрдә театральләштерү элементларын куллану уку эшчәнлеген җанландырып җибәрүгә этәрә.

Театр эшчәнлеге-аралашуның иң төгәл моделе, чөнки ул чынбарлыкны чагылдыра һәм анда, тормыштагы кебек, партнерларның сөйләме һәм сөйләм тәртибе үзара бәйләнгән. Күпләр театральләштергән уеннарда рәхәтләнеп уйный. Чөнки алар тормышны чагылдыра һәм шул ук вакытта, турыдан-туры уен шартларында, тел өйрәнү бара. Татар телен өйрәнгәндә, телдән монологик һәм диалогик сөйләм кулланыла, мәсәлән, һава торышы, мәктәп, сыйныф, гаилә һәм башка темаларга кыска тасвирлаулар. Күпләр бу сүзләрне, сүзтезмәләрне, кыска җөмләләрне ятлыйлар, әмма, кирәк очракта, аларны ничек кулланырга белмиләр. Шуңа күрә дәресләрдә без балалар белән реаль тормышка якынрак рольле уеннар да уйнарга тырышабыз. Бу вакытта укучылар өйрәнелгән сүзләрне, сүзтезмәләрне, эмоцияләрне иркенрәк кулланалар. Мәсәлән, "танышу» темасына кагылышлы лексиканы без «кафеда», «театрда», «автобуста», «паркта ", “кунакта”, “экскурсиядә” кебек ситуатив биремнәрне сәхнәләштерү аша өйрәнергә тырышабыз. Мондый эш алымын кулланганда, балаларның сүзлек байлыгы арта, өйрәнгәннәрен дөрес куллана белүгә этәрә, үз-үзләрен тотышлары да үзгәрә, иптәшләре алдында кыенсынулары да кими төшә.

Татар теле дәрессләрендә театр эшчәнлеге элементларын кулланганда, укучылар әңгәмәдәшне тыңларга, ишетергә өйрәнәләр. Бу дәрес этабының аудирование (ишетеп аңлау) этабын алыштыра. Дәрестә театр эшчәнлеген куллану шулай ук шигырьләр һәм җырлар өйрәнүне, рольләр буенча укуны, театраль хәрәкәтләрне җанландыруны (сүзләр язу һәм аны уку), сценарийлар булдыруны күздә тота. Мәсәлән, Г.Тукайның "Кызыклы шәкәр", "Сабыйга", "Эш беткәч, уйнарга ярый" кебек балалар шигырьләрен, "Шүрәле", "Су анасы" әкиятләрен өйрәнү.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә театр эшчәнлеген куллану укучыларның күзаллауларын киңәйтергә, хәтерне, фикер йөртүне, күзәтүчәнлекне арттырырга, сөйләм телен (коммуникацияне) үстерергә

мөмкинлек бирә, телене өйрәтүгә кызыксынуларын арттыра, тел өйрәнүне мавыктыргыч сәнгатькә әверелдерә.

# «Развитие творческой активности детей в театрализованной деятельности».

**Хузина Ильсеяр Дильфасовна**,
*учитель английского языка,*
*муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Татарско-Суксинская средняя общеобразовательная школа» Актанышского муниципального района Республики Татарстан.*

Современным детям, избалованным фильмами, красивыми игрушками, всевозможными развлечениями, театр нужен не меньше, чем детям прошлых поколений. Ведь театр - один из самых таинственных и прекрасных видов искусства. Только в театре человек может раскрыться полностью, выразить свои эмоции, не боясь стать смешным, прожить не одну, а сотни жизней - таких разных и загадочных.

Для того чтобы научиться понимать прекрасное в искусстве и в жизни, научиться творить, необходимо пройти длинный путь накопления эстетических впечатлений, зрительных и слуховых ощущений. Очень важно создать условия для определенного развития эмоциональных и познавательных процессов у школьников, в том числе и при помощи театрализованной деятельности.

Актуальность моей темы состоит в том, что театрализованные игры являются благоприятной средой для творческого развития способностей детей, так как в ней особенно проявляются разные стороны развития ребенка. Эта деятельность развивает личность ребенка, прививает устойчивый интерес к литературе, музыке, театру, совершенствует навык воплощать в игре определенные переживания, побуждает к созданию новых образов, побуждает к мышлению.

В каждом ребенке с самого рождения есть творческое начало, которое в течение жизни проходит большое количество изменений в разных ситуациях, в которых находится сам ребенок: либо развивается, либо наоборот затухает,

так и не раскрывшись. И вследствие этого, перед его родителями, а также взрослыми, окружающими ребенка, возникает задача не нанести вред, не «уничтожить» в детях их творчество, а напротив помочь им идти в нужном направлении.

Включение ребенка в театрализованную деятельность создаёт огромные возможности для развития его творчества, а именно:

- обеспечивает целостность и глубину воздействия, обусловленную синкретичностью данного феномена, включающего ритмические, музыкальные, словесные воздействия, а также воздействие игрового пространства, усиленное эффектом групповой деятельности;

-позволяет создавать ситуацию импровизационного действия, которая дает участникам высокую степень свободы самовыражения;

-обеспечивает безоценочность ситуации, что позволяет каждому участнику более полно и адекватно выражать собственные чувства, не опасаясь оценки и сравнения;

- создает атмосферу коллективного эстетического переживания, что является значимым фактором успешности, обеспечивая благоприятный эмоциональный фон.

Театрализованные игры дают большой простор для творческих проявлений ребёнка. Они развивают творческую самостоятельность детей, побуждают к импровизации в составлении небольших рассказов и сказок, поддерживают стремление детей самостоятельно искать выразительные средства для создания образа, используя движения, позу, мимику, разную интонацию и жесты.

Для успешного формирования творческой активности детей в театрализованной деятельности необходимо соблюдать ряд условий:

- создавать условия для развития творческой активности детей в театрализованной деятельности;

- приобщать детей к театральной культуре;
- обеспечивать взаимосвязь театрализованной с другими видами деятельности;
- создавать условия для совместной театрализованной деятельности детей и взрослых.

Итак, одним из самых эффективных способов воздействия на ребенка является театрализованная деятельность, в которой наиболее ярко проявляется принцип обучения: учить, играя!

Очевидно, что театрализованная деятельность учит детей быть творческими личностями, способными к восприятию новизны, умению импровизировать. Нашему обществу необходим человек такого качества, который бы смело, мог входить в современную ситуацию, умел владеть проблемой творчески, без предварительной подготовки, имел мужество пробовать и ошибаться, пока не будет найдено верное решение.

В соприкосновении с театром вырастают активные творческие личности, способные выходить на прямое общение с другим человеком, имеющие внутреннюю потребность и возможность изменить окружающий мир, сделать его более совершенным.

И в нашей школе, и в детском саду ведутся кружки театрального искусства на английском языке. Участвуем в различных конкурсах и занимаем призовые места. Мы инсценировали сказки: «Семеро козлят», «Гадкий утенок», «Три поросенка», «Теремок» и отрывок из произведения М.Твена «Приключения Тома Сойера»

Таким образом, творческие способности – это индивидуальные особенности качества человека, которые определяют успешность выполнения им творческой деятельности различного рода.

Школьный возраст даёт прекрасные возможности для развития способностей к творчеству. И от того, насколько будут использованы эти

возможности, во многом будет зависеть творческий потенциал взрослого человека.

# СЕКЦИЯ 2 «ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ТЕАТРАЛИЗОВАННОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ В РАЗВИТИИ РЕЧИ ДОШКОЛЬНИКОВ» (ДЛЯ ПЕДАГОГОВ ДОШКОЛЬНЫХ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ)

## Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсешендә театр эшчәнлегенең әһәмияте

**Авзалова Илюза Ильфаковна**
*Муниципальное бюджетное дошкольноеобразовательное учреждение*
*Муслюмовский детский сад общеразвивающего вида «Кубэлэк»*
*Муслюмовского муниципального районаРеспублики Татарстан*

Театр эшчәнлеге-балалар иҗатының иң таралган төре. Ул балага якын һәм аңлаешлы, табигатендә тирән ята һәм табигый рәвештә чагылыш таба, чөнки бар нәрсә уен белән бәйле. Баланың тирә-юньдәге тормышыннан алган тәэсирләре тере образларга һәм гамәлләргә әверелергә тели. Образга кергәч, ул күргәннәрен һәм аны кызыксындырганнарын охшатырга һәм зур эмоциональ ләззәт алырга тырышып, теләсә нинди роль уйный.

Театральләштерелгән эшчәнлекнең тәрбия мөмкинлекләре киң. Анда катнашып, балалар яңа образларлар белән таныша. Психик үсеш белән тыгыз бәйләнгән һәм сөйләмне камилләштерүдә дә бик актив. Персонажларның репликаларын, үз сүзләрен чагылдыру өстендә эшләү процессында сизелмичә, баланың сүзлеге активлаша, сөйләменең тавыш культурасы камилләшә, аның интонацияле төзелеше камилләшә. Башкарыла торган роль, әйтелгән репликалар, баланы ачык итеп аңлатырга кирәклегенне күздә тота. Аның диалогик сөйләме, грамматик төзелеше яхшыра. Театральләштерелгән эшчәнлек баланың хисләрен, кичерешләрен һәм ачышларын үстерү чыганагы булып тора, аны рухи кыйммәтләргә җәлеп итә дип бәхәсләшергә була. Бу-конкрет, күзгә күренеп торган нәтиҗә. Әмма театральләштерелгән дәресләр баланың эмоциональ өлкәсен үстерә. Шулай итеп, театральләштерелгән эшчәнлек-балаларда эмпатия үсешенең мөһим чарасы, ягъни кешенең эмоциональ халәтен мимика, ишарәләр, интонация буенча таный белү, үзен

төрле ситуацияләрдә аның урынына куя белү, ярдәм итүнең адекват ысулларын табуда чагыла.

Театральләштерелгән эшчәнлек һәр әдәби әсәр яки мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен әкият һәрвакыт әхлакый юнәлешкә (дуслык, игелек, намуслылык, кыюлык һ.б.) ия булуы аркасында үз-үзеңне тоту тәҗрибәсен формалаштырырга мөмкинлек бирә. Театральләштерелгән эшчәнлек балага күп проблемалы ситуацияләрне теләсә нинди персонаж йөзеннән чишәргә мөмкинлек бирә. Бу оялчанлыкны, үз-үзеңә шикләнүне, оялчанлыкны җиңәргә булыша. Театральләштерелгән уеннарның характерлы үзенчәлекләре-аларның әдәби яки фольклор нигезе һәм тамашачыларның булуы (Л.в. Артемова, Л. в. Ворошнина, л. с. Фурмин һ. б.). Аларны ике төп төркемгә бүлеп була: драма һәм режиссерлык (аларның һәрберсе үз чиратында берничә төргә бүленә).

Уеннарда-драматизацияләрдә бала, «артист» сыйфатында роль уйнап, мөстәкыйль рәвештә телдән һәм телдән булмаган экспрессивлык чаралары комплексы ярдәмендә образ тудыра. Режиссерлык уенында «артистлар-уенчыклар яки аларның урынбасарлары, ә бала, «сценарист һәм режиссер» буларак, «артистлар»белән идарә итә.

Театральләштерелгән эшчәнлектә балаларның иҗади активлыгын уңышлы формалаштыру өчен берничә шартны үтәргә кирәк:

-театральләштерелгән эшчәнлектә балаларның иҗади активлыгын үстерү өчен шартлар тудыру;

-балаларны театр культурасына тарту;

-театральләштерелгән эшчәнлекнең башка төрләре белән бәйләнешне тәэмин итү;

Мин театральләштерелгән эшчәнлекне иртәнге һәм кичке сәгатьләрдә режим вакытында оештырам; төрле дәресләргә (музыка, танып белүгә һ.б.) кертәм, бу-баланың шәхесен үстерүнең төп чараларының берсе.

Мондый уен аша балалар спектакльнең уңай персонажлары аша дуслык, дөреслек, җаваплылык үрнәген алалар. Театральләштерелгән эшчәнлек мәктәпкәчә учреждениесенең педагогик процессында мөһим урын алып торырга, балаларның иҗади үсешенә, аларда шәхес культурасы базисы булдыруга ярдәм итәргә тиеш.

Театральләштерелгән зоналарда балалар яраткан әкият сюжетларын уйнаталар, репетицияләр үткәрәләр, иллюстрацияләр карыйлар. Болар барысы да балаларга фантазияларын баетырга һәм фантазия дөньясына чумырга мөмкинлек бирәләр.

Балаларның иҗади сәләтләрен театральләштерелгән эшчәнлектә үстерү буенча эшне музыка җитәкчесе һәм ата-аналар белән тыгыз элемтәдә алып барабыз. Театральләштерелгән тамашалар әзерләүдә балалар бакчасының бөтен коллективы катнаша: тәрбиячеләр белән берлектә декорацияләр, афишалар әзерлибез, костюмнар эскизларын әзерлибез. Музыка җитәкчесе белән бергә музыкаль әсәрләр сайлыйбыз, аларны өйрәнәбез, бию кую өстендә эшлибез. Хезмәттәшләребез белән үз тәҗрибәбезне уртаклашабыз.

## Әдәбият исемлеге:

Акулова О. театральләштерелгән уеннар. // Мәктәпкәчә тәрбия. - 2005. - № 4. - С. 24.

Бочкарева Л. П. мәктәпкәчә яшьтәге балаларның театр-уен эшчәнлеге: мәктәпкәчә белем бирү белгечләре өчен методик кулланма. - Ульяновск, ИППРО, 1993. - 48 с.

Кошман и. П. балалар бакчасында Театр ("сезнең балагыз дөньясы»сериясе). - Ростов н/Д: Изд - «Феникс» та, 2004. - 320 с.

Маханева М. Д. балалар бакчасында театральләштерелгән дәресләр: мәктәпкәчә учреждениеләрдә эшләүчеләр өчен кулланма. - Мәскәү. "Сфера сәүдә үзәге» нәшрияты, 2004. - 128 с.

Петрова Т.И., Сергеева Е. Л., Петрова Е. С. балалар бакчасында театральләштерелгән уеннар: методик тәкъдимнәр белән барлык яшь төркемнәре өчен

дәресләр эшләү. - М.: мәктәп матбугаты (мәктәпкәчә тәрбия һәм укыту. «Мәктәп укучыларын тәрбияләү»журналына кушымта. Чыгарылышы 12), 2000. - 128 с.

## «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм телен үстерүдә театр эшчәнлегенең роле»

**Аглямова Лилия Булатовна** *воспитатель,*
*МБДОУ Муслюмовский детский сад общеразвивающего вида «Кубэлэк»*
*Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан*

Сәхнәләштерелгән эшчәнлекнең тәрбияви мөмкинлекләре бик киң икәнлеген күрдем. Балалар бу эшчәнлектә катнашып, образлар, төсләр, авазлар аша әйләнә - тирә куйган сорауларга җаваплар таптылар, уйларга, анализ ясарга, нәтиҗәләр чыгарырга, гомумиләштерергә өйрәнделәр.

Балаларның диалогик сөйләмнәре, аның грамматик төзелеше яхшыруы күзәтелде. Сәхнәләштерелгән уеннар, балаларның хисләрен, тирән кичерешләрен, һәм ачышларын үстерүгә башлангыч булып торды. Шул ук вакытта балалар персонажларның хәленә керергә, алар белән бергә борчылырга өйрәнделәр.

Сәхнә эшчәнлеге, балалар өчен язылган һәр әдәби әсәрнең яки әкиятнең әхлакый юнәлештә булуы, балаларда дуслык, михербанлылык, гаделлек, батырлык сыйфатлары тәрбияләде. Әкияткә нигезләнеп, бала, тормышны акылы белән генә түгел, йөрәге белән аңлавы күренде. Яхшыга, һәм яманга үз карашларын да ачык күрсәттеләр. Алар яраткан геройларына охшарга тырыштылар. Балаларның шушы үзенчәлеге безгә сәхнә эшчәнлеге аша уңай йогынты ясарга мөмкинлек бирә дә инде. [2, 6 б.]

Сәхнә эшчәнлеге балаларга төрле проблемалы ситуацияләрне билгеле бер персонаждан чыгып хәл итәргә ирек бирде. Бу исә балаларда оялуны, үз-үзенә ышанмауны, кыюсызлыкны җиңүгә китерде. Сәхнә эшчәнлеге балалар белән театральләштерелгән шөгыльләр балаларның күп яклап үсүенә китерде, үзләрен иркен тотарга мөмкинчелек тудырды дигән нәтиҗәгә килдем.

Шунысы эш барышында ачыкланды, сәхнә эшчәнлеге аз гына төркем балалары белән оештырылырга тиеш. Бу һәр балага индивидуаль якын килергә мөмкинлекләр бирә.

Тыңлаганда, сөйләгәндә, үз әкиятләрен тудырганда бала хыяллана, уйлап таба. Тәркем бүлмәсендә оештырган — әкият почмагыннан аларны аеруы бик читен. Балаларның үзләренә ярашлы итеп тектерелгән әкият геройлары костюмнарын киеп, күп кенә образлар тудырдылар. Өйрәнгән әкиятләрне өстәл театрында уйнау да балалар өчен бик тә кызыклы булды. Уеннарда, әкиятләрне сәхнәләштергәндә балаларның бер өлеше актив катнашса, арада пассив, уенда катнашырга бик теләмәүчеләр күзәтелде. Андый балалар белән аерым эшләүне кулай күрдем. ТРИЗ элементларын куллану да уңай нәтиҗәләр бирде. Балалар белән әкиятнең ахырын үзгерттек, яңа әкиятләр уйлап таптык, яңа геройлар катнаштырдык. Бу алымнар бик мавыктыргыч булды.Үз вариантларын яклап, бер - берсе белән бәхәсләштеләр, бер – берсен тыңлый белү, аралашу культурасына өйрәнделәр.

Әкиятләрне балаларның ничек кабул итүе аның сөйләнү рәвешенә дә бәйле. Шуңа да әкиятләрне балаларга берничә тапкыр укырга тырыштым. Балалар игътибар белән тыңласын өчен, аларны алдан әзерләдем.

Ата - аналарга – “Әкиятләр илендә” папка булдырдым, аны яңа материаллар белән тулыландырып бардым. Балаларны саф, матур сөйләмгә өйрәтүдә әти- әниләрнең дә тартылуы уңышка китерде. Уртак эш үз чиратында балаларда аваз кимчелекләрен бетерүдә ярдәм итте.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: соңгы елларда халыкның үз туган теленә, мәдәниятенә игътибары көчәя бара. Балалар бакчаларында өйрәтү процессын модернизацияләү без тәрбиячеләрдән иҗади активлык, үз юлын, үз технологиясен табуны һәм гамәли кулллануны таләп итә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Бала бишеге-гомер ишеге. Башлангыч сыйныф укытучылары, балалар бакчаларында, милли төркемнәрдә тәрбиячеләр, ата-аналар өчен халык авыз иҗаты әсәрләре җыентыгы. 3 нче басма: Яр Чаллы, “Идел-йорт” нәшрияты, 2002.
2. Иң матур сүз: Ата - аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия. Казан, Мәгариф, 2000.
3.Иң татлы тел – туган тел: Балалар бакчасында сөйләм үстерү буенча методик кулланма. М.Ф.Кашапова. Казан: Мәгариф, 2004.

## Развитие речи детей через театрализованную деятельность.

**Салахова Лилия Сириновна**, *воспитатель,*
*МБДОУ-детский сад «Березка»*
*Тукаевского муниципального района, РТ.*

Интересным, увлекательным и актуальным направлением в дошкольном воспитании является театрализованная деятельность.

Знакомство с театром происходит в атмосфере волшебства, праздничности, приподнятого настроения.

В работе с детьми по организации театрализованной деятельности опираюсь на работы современных педагогов: Л.В. Артемовой «Театрализованные игры дошкольников», Т.Н.Дороновой «Играем в театр», в которых рассмотрены особенности организации театрализованной деятельности детей в дошкольном возрасте.

Именно театрализованная деятельность позволяет решать многие педагогические задачи, касающиеся формирования выразительности речи ребенка.

**Цель:** развивать эмоциональные, интеллектуальные, коммуникативные особенности ребенка - средствами детского театра, развивать артистизм и навыки сценического воплощения.

**Задачи:**

- стимулировать у детей интерес к знакомству с историей театра, умение воспринимать художественное слово и понимать его значение;

- активизировать и совершенствовать словарный запас, грамматический строй речи, звукопроизношение, навыки связной речи;

- воспитывать у детей уважительного отношения к сверстникам и старшим, учиться работать вместе и самостоятельно.

Игры - драматизации – это особые игры, в которых ребёнок разыгрывает знакомый сюжет или придумывает новый. Важно, что в такой игре ребёнок

создаёт свой маленький мир и чувствует себя хозяином, творцом происходящих событий. Ребенок в игре превращается и в актёра, и в режиссёра, и в сценариста. Он озвучивает героев, придумывает историю, проживает то, что в обычной жизни ему прожить бывает нелегко.

Самый простой вариант игры-драматизации в домашних условиях – спектакль игрушек. Детям в возрасте около 2,5 лет уже доступны классические сказочные сюжеты – например, «колобок» или «теремок». Достаточно лишь подобрать необходимые для спектакля игрушки из тех, которые у вас есть. Они должны быть средних размеров и с выразительной внешностью.

**Театр маленьких пальчиков.** Большой популярностью пользуется у детей и взрослых пальчиковый театр. Он особенно полезен для развития мелкой моторики рук, а с 5–6 лет постепенно готовит руку к письму. Ребенку можно показывать спектакли на пальчиках. Наденьте сначала на свой палец одну куколку и разыграйте с ней простой сюжет, любимую сказку. Пальчик-персонаж шевелится, танцует, подпрыгивает, общается с вами и малышом, создавая ощущение того, что он живой актёр.

В ходе игры хорошо использовать настольную ширму, за которой будут меняться актёры и декорации.

**Театр на столе.** Дети очень любят настольно-плоскостной или объёмный театр. Сейчас в продаже можно найти большое количество вариантов такого театра. Это картонные или фанерные силуэты на устойчивых подставках. Все персонажи окрашены с двух сторон и отлично скользят по столу.

Играя, ребёнок с удовольствием озвучивает всех персонажей сказки. Ему приходится придумывать к каждому герою (а это не только звери и люди) свой неповторимый голос. Такая игра развивает и воображение, и речь, и голосовой диапазон ребёнка.

**Домашний кукольный театр.** Наиболее богатые возможности для игры-драматизации даёт настоящий кукольный театр, который вполне можно устроить дома с помощью кукол «БИ-БА-БО». Это куклы с твёрдой головой, к которой приклеено туловище-перчатка из ткани. Указательный палец управляет головой, а большой и средний – руками.

Возможности этих кукол безграничны. Для самых маленьких театралов подойдут простые спектакли с одним действующим персонажем. Если в доме две куклы «би-ба-бо», можно разыгрывать с ребёнком разные придуманные сценки или истории из жизни.

Играя, ребёнок забывает обо всём. Он забывает о реальном мире, в котором живёт. Всё его сознание устремляется в мир фантазии и сказки, и ребёнок раскрывается. Застенчивый малыш во время спектакля может взять на себя роль.

Сейчас появилось много игрушек, которые при нажатии на кнопочку «сами» произносят те или иные слова, выполняют запрограммированные движения. Но зачастую ребёнок быстро теряет к ним интерес, ведь такая игрушка не может стать в его руках артистом – она не может выразить его переживания, говорить его голосом, выполнять нужные ему действия. Детям для полноценного развития необходимо фантазировать, придумывать различные сюжеты, вживаться в разные образы, которые далеко не всегда соответствуют «готовым» фразам или механическим жестам.

В игре ребёнок развивается. При этом игрушки, которые мы приобретаем для своих детей, могут либо тормозить игру, либо стимулировать и совершенствовать её.

**Используемая литература:**

1. «От рождения до школы» примерная основная общеобразовательная программа дошкольного образования / Под ред. Н.Е. Вераксы, Т.С. Комаровой, М.А. Васильевой. – М.: МОЗАЙКА-СИНТЕЗ, 2012.-336с.

2. «Занятия по театрализованной деятельности в детском саду», М.Д. Маханева, Москва, 2004.
3. Страковская В.Л. 300 подвижных игр для оздоровления детей от 1 года до 14 лет. – М.: Новая школа, 1994, - 288с.

# Театр эшчәнлеге аша балаларның сөйләм телен үстерү

**Хаертдинова Ләйсән Радиковна,** *тәрбияче ,*
*«Батыр» 111нче санлы балалар бакчасы-баланың*
*аң белемен үстерү үзәге», Яр Чаллы*

Мәктәпкәчә яшь ул – баланың көчле үсү һәм камилләшү, беренчел белемнәр алу чоры. Әлеге әһәмиятле чорда бала үзен чолгап алган тирәлекне, тирә-юньдәге күренеш һәм предметларны танып белә; анда әйләнә-тирә дөнья турында башлангыч белемнәр системасы формалаша. Бу чор – баланың шәхес буларак тәрбияләнүенә беренче адымнар салынган җаваплы чоры. Бу чорда баланың холкы, тирә-юньгә карата фикере формалаша һәм аның ни рәвешле булуы күп очракта тәрбиядән һәм тәрбиячеләрдән дә тора.

Икенче кечкенәләр төркемендә (3-4 яшь) балаларда игътибар, хәтер, фикерләү, күзаллау, сөйләме көчле үсеш ала. Уенның төп үзенчәлеге, аның шартлы рәвештә булуында. Кече мәктәпкәчә яшьтәге бала уенының төп эчтәлеген уенчыклар һәм предметны алмаштыра торган җиһазлар тәшкил итә. Бу яшьтә балаларның уены озак вакытка сузылмый. Балалар уенда бер-ике роль һәм гади сюжетлар белән чикләнәләр.Яшь үзенчәлекләреннән чыгып әлеге яшь чоры- театр эшчәнлеге буенча беренче нигезләрне салу өчен бик кулай чор.  Шул сәбәпле, без төрле  театр  төрләре белән эшлибез : бармак уеннары, өстәл театры ,әкият-драматизация, курчак , магнит һәм бармак театрлары .

Курчак театры балаларны сихри дөньяга алып керә, аларнын иҗади фикерләү сәләтен ачарга ярдәм итә, сойләм телен үстерә, эстетик һәм әхлакый тәрбия бирә. Курчак театрларын уйнау балаларның хәтерен, игътибарын, күзаллау сәләтен, сөйләм чисталыгын үстерергә ярдәм итә. Курчаклар белән уйнаганда баланың сүз байлыгы арта, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләнә. Аның хәтере үсә. Рольне уйный - уйный, бала әкият дөньясына кереп китә,

татар телен истә калдыру җиңеләя. Һәр бала катнашучы һәм караучы буларак функция үти. Алар үзләренең хаталарын, ялгышларын күрергә өйрәнәләр һәм тагын да матуррак, аңлаешлырак уйнарга тырышалар. Курчаклар белән уйнаганда балаларга таныш һәм аларга ошаган әкиятләрне сайлап алабыз. Мәсәлән: "Шалкан", "Теремкәй", "Йомры икмәк" һ.б.

Сөйләм үсешендә бармак уеннары һәм сүзле-хәрәкәтле уеннар җитди урын алып тора.Баланың акылы хәрәкәттә үсә.Бөек педагог В. А. Сухомлинский "Баланың фикер йөртүнең чыганагы бармак очларында урнашкан",- дип язган. Чынлап та ,балаларның баш миен,психикасын өйрәнүче галимнәр кул чуклары функцияләрен үстерүнең зур әһәмияткә ия булуы турында күп сөйлиләр.Гомеренең беренче көннәреннән үк бармак гимнастикасы ясаганда,аннары рәсемнәр төшергәндә,вак предметлар белән уйнаганда, баланың бармаклары мөмкин кадәр күбрәк хәрәкәтләнә. Шул сәбәпле, төркемебездә бармак театры да киң кулланылыш алды. Балаларның бармакларын ныгыту өчен "Бармак театры" оештыру бик файдалы. Тик шуны истә тотарга кирәк: бармак уеннары биш минуттан озаграк булмасын,әлеге яшь чорында бу сөйләм функциясен стимуллаштыру өчен бик җиткән.

Магнитлы һәм өстәл театрлары уйнау да балаларда күп кызыксынучанлык уята.Таныш әкиятләрнең эчтәлеген геройларның сөйләме аша тапшыру, рольләргә бүленеп, интонация белән сөйләүне булдыру киң үсеш ала.Кечкенә уенчыклар ярдәмендә рольләргә керү баланың вак моторикасына уңай йогынты ясый. Шулай ук төркемдә аңлашып,киңәшләшеп уйнау күнекмәләре дә психологик яктан уңай халәт тудыра.

Уен-драматизацияләр аша бала үсеш ала, тирә-юньне танып белә һәм аралаша. Билгеле инде, театр уйнау яки театрлаштырылган уеннар

оештыру өчен иң элек шартлар тудырыла. Бу эшкә тәрбияченең күп хезмәте һәм көче куела. Балаларда эмоциональ һәм сөйләм чагылышын үсә, балаларга театр сәнгате өлкәсендә беренчел күнекмәләр (мимика, ишарәләр, тавыш куллану) бирелә. Балалар театр, аның төрләре, атрибутлар, костюмнар, декорацияләр турында күзаллауларын киңәйтәләр.Ата-аналар да бу эшчәнлектә катнашу нигезендә, тыгыз элемтә формалаша. Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү нәтиҗәсендә балаларның интонацияләре яхшыра, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арта, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туа. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсә.

Шул рәвешле, театр эшчәнлеге өстендә даими рәвештә эш алып бару- башлангыч этапның ныклы нигезе. Театр баланың рухи һәм иҗади потенциалын ачуда һәм социаль мохиткә җайлашырга реаль мөмкинлек бирә.Мондый тирәлектә тәрбияләнгән балалар ихлас, игелекле гамәлләр генә кылыр дип ышанабыз.

## Кулланылган әдәбият

1.Ф.В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И.Җ. Хәбибуллина “Туган телдә сөйләшәбез”.Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү(икенче кечкенәләр өчен методик кулланма/.-Казан: Татар.кит.нәшрияте,2012-191 б.

2. Туган телдә сөйләшәбез. Методик кулланма / Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ. – Казан: Фолиант, 2013.- 224 б.

3. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. — Казан: РИЦ, 2011. — 560 б.

# Мәктәпкәчә яшьтәге балалар тормышында Театр

**Халиуллина Венера Васыйл кызы**

*тәрбияче, «Күбәләк» балалар бакчасы.*

Мәгариф өлкәсендәге үзгәрешләр мәктәпкәчә тәрбиягә дә зур йогынты ясый. Мәгарифтәге юнәлешләр үзгәреше- белем формалашу ориентациясе- күпкырлы үсеш күнекмәләре формалаштыру бурычы бөтен үсеш этабында да иң мөһим чара булып тора.

Мәктәпкәчә тәрбия- мәгариф өлкәсендә беренче һәм иң җаваплы буын булып тора. Мәктәпкәчә яшьтә туган телне белү, баланың иң мөһим табышы булып тора. Чөнки бу яшьтә бала бик тиз үзләштерә, истә калдыра. Шуңа күрә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларда сөйләм үстерү иң мөһим проблема. Халыкның рухи мирасы, күңел җәүһәрләре балага дөрес, нәтиҗәле тәрбия бирүдә бай хәзинә.Табигать тарафыннан кешегә сәләтләр төрлечә бирелә, ләкин даими күнегүләр ярдәмендә һәр баланың сәләтен үстерергә мөмкин.

Сөйләм телен үстерү- ул телнең образлы, эмоциональ булуын да ачыклый. Кешенең сөйләме образлы, сәнгатьле булырга тиеш.

Психологик әдәбиятны анализлау, сөйләм сәнгатьлелеге интеграль характерны кирәклеген күрсәтә. Ул вербаль (мимика, ишарә,кыяфәт) һәм вербаль булмаган(интонация, лексика, синтаксис) чараларын үз эченә ала.

Телләр үзләштерү байлык! Республикабызның киләчәге булган балаларның дәүләт телләрен үзләштерү процессына мәктәпкәчә яшьтә үк старт бирү-мәктәп, югары уку йортларында белем алу этабы өчен яхшы фундамент әзерләү ул.

Балаларга тәкъдим ителгән укыту-методик комплектлары нигезендә шөгыльләнүләрен, беренче чиратта, мавыктыргыч һәм югары дәрәҗәдә профессиональ итеп оештыру зарурлыгын кабат-кабат ассызыкланды. Заманча педагогик технологияләр белән янәшә мультимедиа чараларын һәм

Интернет мөмкинлекләреннән киң файдалану өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте мул ярдәм итте.

Сәнгатьле сөйләм формалаштырганда балага белем бирү шартлары гына түгел, ә аларны эшкәртергә һәм үзләренең карашын билгеләргә дә мөмкинлек бирә. Моның өчен иң әйбәт чара булып театр һәм театральләштерелгән уеннар аерым урын алып тора, чөнки уен мәктәпкәчә яшьтәге балалар эшчәнлегенең төп төре булып тора. Театр-иң кулай эшчәнлек төрләренең берсе, ул әхлакый һәм сәнгать тәрбиясе, фантазия үсеше, мөстәкыйльлек, инициатива һ.б. белән бәйле күп кенә педагогика һәм психология проблемаларын чишәргә мөмкинлек бирә. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның театр-уен эшчәнлеге гомумиләштерелгән төшенчә: уеннар-драматизация, ширмадагы төрле тамашалар, өстәл, бармак, күләгәле театрлар. Театральләштерелгән уеннар-билгеле бер әдәби әсәрләр мимика, ишарә, интонация кебек экспрессив чаралар ярдәмендә уйнатыла торган тамаша, конкрет образлар тудырыла.

Театр эшчәнлегенең мөһим бурычлары:

Беренче бурыч, балаларны бүтән кешенең хәлен аңларга, үз хисләрен белдерә белергә, дуслык тәрбияләргә, бергәләп эш итә белергә өйрәтү.

Икенче бурыч, сөйләм культурасын формалаштыру. Театральләштерелгән уен баланың сөйләм үсешенә зур йогынты ясый. Театр эшчәнлеге артикуляция аппаратын камилләштерә. Бала туган телнең байлыгын үзләштерә. Геройларның тәртибенә, характерына туры килгән интонацияләрне һәм экспрессив чараларны кулланып, бала ачык итеп сөйләү культурасын аңлар өчен тырыша. Балалар әсәрнең эчтәлеген, логикасын һәм вакыйгалар эзлеклелеген яхшырак үзләштерәләр.

Өченче, әһәмиятле мәсьәлә - театр мәдәниятенә нигез салу. Театр дәресләрендә балаларны театр сәнгатенең терминологиясе төшенчәләре белән таныштыралар, балаларның театр турындагы белемнәрен киңәйтәләр.

Әгәр дә ул уенда үзе катнашса, баланың тәэсирләре тагын да яктырак була.

Театр-курчаклар яшәгән дөнья. Балалар сәхнәдәниләр булганына ышана, алар курчакларны тере затлар белән кабул итәләр, алар белән бәхәсләшергә, уңай персонажга булышырга өнди. Театр балаларны актив булырга өйрәтә, бу иң кыйммәтле нәрсә.

Балагызны театр белән аралашудан мәхрүм итмәгез. Театр сәнгатенең тылсымы белән бүген үк таныштыра башлагыз.

**Файдаланылган әдәбият.**

1.Борһанова Р.А., Юсупов Ф.Ф. Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы, 2004.

2.Закирова К., Гаффарова С. “Әткәм-әнкәмнең теле”, 2010.

3.”Иң матур сүз" (хрестоматия)

4. 8. Шәрәфетдинов З.Т. Балалар бакчасында татар теле өйрәнү.

5.Н.Н. Григорьева, «Мәктәпкәчә яшьтәге балалар тормышында театрның роле», 2014.

**«Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәләтләрен һәм иҗади потенциалын үстерүдә уңай шартлар тудыру»**

**Хәлиуллина Нәфисә Ирхәт кызы**

*тәрбияче, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль*

*бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе Мөслим авылы*

*гомумүстерешле "Күбәләк" балалар бакчасы*

Балаларның аерым бер сәләткә ия булулары – табигатьнең иң кызыклы һәм серле күренешләреннән берсе. Сабыйның мәктәпкәчә яшьтәге чоры сәләтне үстерүнең "сензитив" чоры санала. «Сензитив» сүзе латин теленнән кергән. Sēnsus – хис, тоемлау, аңлау кебек мәгънәләрне белдерә. Сензитив үсеш чоры дәвамында организм әйләнә-тирә мохиткә карата югары сизгерлеккә ия, шул ук вакытта физиологик һәм психологик яктан да үз-үзеңне тота белү һәм аң-белемнең яңа формаларын үзләштерергә әзер.

Бала, дөньяга килгәндә ук, билгеле бер потенциалга ия була. Уңай шартлар тудырылган очракта, ул, нәтиҗәле үсеш алып, балага зур уңышларга ирешергә ярдәм итә.

Балаларның сәләтләрен ачыклау һәм алар белән эшләү белем бирү өлкәсе хезмәткәрләре өчен актуаль мәсьәлә булып тора, шулай ук дәүләт мәгариф сәясәтенең дә өстенлекле юнәлешләреннән санала. Эш тәҗрибәсе күрсәткәнчә, мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында яшьтәшләреннән үсешенең бик нык алга китүе белән аерылып торганнары була. Гадәттә, алар тәкъдим ителгән яңа материалны тиз үзләштереп алалар, яшьтәшләре белмәгән вакыйга һәм проблемалардан хәбәрдар, ишеткән яисә укыганны тиз истә калдыралар, акыл хезмәте таләп иткән катлаулы мәсьәләләрне чагыштырмача җиңел хәл итәләр, күп сорау бирәләр, кызыксынучан булалар, үзенчәлекле, ягъни оригиналь фикер йөртәләр һәм көтелмәгән җаваплар

тәкъдим итәләр, тиз төшенүчән, күзәтүчән булалар һәм барлык яңа төшенчәләрне отып алалар. Болар барысы да – сәләтле бала сыйфатлары:

• Һәр баланың кайсы өлкәдә булса да сәләте була, сәләтсез балалар булмый. Әмма шул сәләтне кече яшеннән үк күреп алырга һәм аны үстерү өстендә эш алып барырга кирәк. Бу – балалар бакчасының шәхес тәрбияләүдәге төп максаты.

• Балаларның иҗади сәләтләрен үстерү өчен иң элек шартлар тудыру мөһим. Яңа стандарт шартларында әлеге мәсьәләне тормышка ашыру өчен гаять күп төрле методлар, ысуллар бар.

• Шәхеснең төрле яклап үсүенә, иҗади сәләтен арттыруда балалар бакчасыннан тыш эшчәнлек зур урын алып тора. Традицион һәм традицион булмаган методларга нигезләнеп, бу эшне нәтиҗәле тормышка ашырып була. Балалар төрле бәйрәм, кичәләрдә теләп катнашалар. Әти-әниләр дә бу эштә читтә калмыйлар.

• «Тел – рухи дөнья көзгесе», – дибез. Чыннан да, туган тел мәктәпкәчә яшьтәге балаларны төрле яктан килгән шәхес итеп тәрбияләүдә мөһим роль уйный. Тел ярдәмендә балалар әби-бабаларның гореф-гадәтләрен, милли традицияләрне үзләштерәләр. Халык авыз иҗаты, кызыклы шигырьләр балаларда аеруча да кызыксыну уята. Мәктәпкәчә чорны шартлы рәвештә берничә этапка бүлеп чыгарырга мөмкин:

**Беренче этап (2-3 яшь).** Хис- тойгы, эмоцияләр җыю чоры. Бу этапта иң мөһиме – хисне уяту. Сәнгать алымнары бу яшь аралыгында бары үсеш фоны буларак кулланыла.

**Икенче этап (3-4 яшь)**. Табигый сәләтнең беренчел сыйфатлары күзәтелә. Әлеге яшьтәге бала шактый актив, теләсә кайсы эшчәнлеккә теләп, яратып алына. Шушы фактны истә тотып, балаларга берничә өлкәгә караган эш төрләрен тәкъдим итәргә һәм һәр баланы күзәтергә кирәк.

**Өченче этап (4-5 яшь).** Кызыксыну, теләк, иҗади эзләнү хас чор. Бу этапта сәләтләре бертөрлерәк булган балаларны өстәмә дәресләр өчен төркемнәргә берләштерергә ярый.

**Дүртенче этап (5-6 яшь).** Табигый сәләтенең ачык күренеп торуы белән характерлана. 5-6 яшьтәге бала бу чорда эшне уңышлы һәм нәтиҗәле итеп башкарырга омтыла.

**Бишенче этап (6-7 яшь).** Профессиональ сәнгатькә беренче адым ясау вакыты. Бу этапта аерым бер балаларның сәләтләре, ачык күренеп, зур үсеш ала. Шуңа күрә аларга өстәмә шөгыль-чаралар тәкъдим итү, башлыча, төрле түгәрәкләр оештыру зарур. Аерым бер балалар белән индивидуаль эш итү дә бик үтемле бу чорда. Болар барысы да баланың табигый сәләтен үстерү өчен ярдәмче фактор. Баланың сәләтләре үсешендә бишенче этап – мәктәпкә әзерлек төркеме. Аерым бер балаларның үсеш дәрәҗәсе шактый югары була. Аларга балалар бакчасында «кысан» була башлый, алар дөньяга беренче адымнарын ясарга әзерләр. Бу вакытта балаларның эшчәнлек даирәсен киңәйтеп, алга таба эстетик һәм интеллектуаль үсеш өчен шартлар булдыру мөһим.

Район һәм республика күләм үткәрелгән төрле конкурсларда балаларның уңышлары шактый.

• “Без Тукай оныклары” конкурсында чыгыш ясап мактауга лаек булдылар,шулай ук төрле дистанцион бәйгеләрдә катнашып киләбез. Балалар үзләренең уңышларын күреп сөенәләр. Бу аларны яңа эшләргә әйди, яңа җиңүләргә җилкендерә.

Шулай итеп, балаларның сәләтләрен үстерү буенча тәрбия һәм белем бирү системасы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) тәрбиячеләр, өстәмә белем бирү педагоглары һәм ата- аналар хезмәттәшлеге барышында тормышка ашырыла торган күчүчәнлек;

2) мәктәпкәчә яшьтә “сенситив”лыкны исәпкә алу;

3) эшне вакытында башлау;

4) балага индивидуаль якын килү;

5) сайлау мөмкинлеге булдыру;

6) комплекслы якын килү;

7) балалар бакчасының мәгариф, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре белән хезмәттәшлек итүе.

Бакчада үткән һәр минут балага шатлык, бәхет китерергә тиеш. Бала эшне теләп, чын күңелдән эшләгәндә генә без чын- чынлап нәтиҗәгә ирешәчәкбез. Без тәрбиячеләр буларак, эшчәнлекне оештырганда, һәрчак баланың уңышын күрә белергә тиешбез. Шул вакытта гына һәр баланың үзенә генә хас яхшы сыйфатын, сәләтен, талантын күрергә була.







**Кулланылган әдәбият:**

1. Е.В. Мигунова. "Театральная педагогика в детском саду" М.: ТЦ Сфера, 2009.

2. Антипина Е. А. Театрализованная деятельность детей в детском саду: игры, упражнения, сценарии. М., ТЦ Сфера, 2003. Маханёва М. Д. Театрализованные занятия в детском саду. // Дошкольное образование № 12. 2002.

3. М.Б.Зацепина "Развитие ребенка в театрализованной деятельности" Москва 2010.

4. Мерзлякова С. И. “Волшебный мир театра” М., Институт повышения квалификации работников образования, 1995.

5. Т.Н.Караманенко, Ю.Г.Караманенко "Кукольный театр - дошкольникам" М.: Просвещение 1982.

6. "Дөрес сөйләшик", Методик кулланма., Казан 1999 ел.

# Түгәрәк алан әкияте

**Хасанова Найля Назифовна**

*МБОУ ДО «Центр детского творчества»*

*Актанышского муниципального района РТ*

Экология дөньякүләм әһәмиятле, мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Ул үзенең актуальлеге белән бүген бөтен кешелек алдына килеп басты.

Табигатьнең киләчәге, бөтенлеге кеше кулында.

Без педагоглар киләчәк белән идарә итәчәк бунны тәрбиялибез.Киләчәгебезнең ни дәрәҗәдә уңышлы булуында безнең күпкырлы хезмәт,омтылыш,максатка ирешү тора.

5-7 яшьлек балалар белән экологик юнәлештә эш оештыру,аеруча отышлы.Чөнки, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга аеруча кызыксынучанлык хас.

Алар бигрәк тә аны урап алган мөһит, тирәлек, табигатькә игътибар итәләр.Табигатьне күзәтү, аны өйрәнү, сакларга омтылу- балаларның рухи дөньясын баета, уйларга өйрәтә.

Табигать ул censored бербөтен.Сулар, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы,табигать күренешләре – узара аерылгысыз бәйләнештә.Экологик тәрбия бирүдә: туган як табигатенә сакчыл караш тәрбияләү; табигать күренешләре һәм бәйләнешләре турында күзаллауларны киңәйтү һәм системалаштыру; экологик белемнәрне пропагандалау бурычларын бер яссылыкта чишүне үземә максат итеп куям.

Эшчәнлегемнең бер юнәлеше булып,экологик темага әкиятләр уйлап чыгару, балалар белән уку, төрле әңгәмәләр, рәсем бәйгеләре үткәрү, шул әкиятләрне сәхнәләштерү тора.

## Түгәрәк алан әкияте.

Көннәрдән бер көнне иртәнге урман сәер тавыштан уянды: зең-зең,зең-зең!Ул да түгел урман хәбәрчесе Саескан шар-шыр,шырт-шырт килеп тавышланды.Кыңгырау чәчәкләренең зеңгелдәвен Саескан тавышы күмеп китте:

-Игътибар, игътибар!Барлык урманда яшәүче кошларга, җәнлекләргә,бөҗәкләргә Йөзъяшәр Имән янына урман аланына җыелырга! Бик зур эш көтелә.Соңламаска!Ашыгырга,вакытында килеп җитәргә!

Күп тә үтмәде Йөзъяшәр Имән үскән алан зур сабантуйны урынына әйләнде.

Иртә таңнан йөререгә яраткан урман тавыклары аскы ботактан урын алганнар.Килеп җитүгә үк Тукраннар шак-шок килеп Имәнне тикшерә дә башлаганнар: авырмыйсыңмы, корткыч бөҗәкләр газапламыймы үзеңне?

Тургайның җыры болытлар өстендә үк ишетелеп алды да тынып та калды.Янәшәдәге кечерәк куак сизелер-сизелмәс кенә селкенеп куйды:Тургай кунган иде, күренми дә диярлек үзе.Күкенең тавышы гына тынлыкны бозып куйды.Мин дә монда,янәсе.Кара карга балаларын күптән очырса да,чыбык-чабыклардан ясаган оясында утыра бирә. Чыпчыклар исә һаман бәхәсләшүләрен дәвам итәләр: саескан хәбәренә ышанып нәрсәгә дип җыелганнар, гаҗәп...

Йөзъяшәр Имән күршсендә үскән Каен ботагында Сыерчыклар урын алган.Аларның оялары да шушы Имәндә: Тукран дуслары әзерләп калдырган кечкенә түгәрәк йортлар алар.

Ала Каргалар җылы кояш нурында кичәге яңгырдан соң канат-каурыйларын төзәтәләр.

Күгәрченнәр җылы җәйне урманда үткәрәләр. Килеп җитүгә Имәннең өске ботагында урын алдылар. Бергәләп гөрләшеп куялар..

Миләш чыпчыклары, песнәкләр, җитез шәүлегәннәр никтер аланга килмәгәннәр, хәбәрне ишетмәгәннәр, күрәсең.

Карлыгачлар да елга ярындагы чокып ясалган ояларыннан чыгып, дәррәү һавага күтәрелделәр дә,болын артындагы сулыкка очтылар.

Куркак куяннар куаклар арасына посканнар: хәерле хәбәр генә булсын.Тиеннәр биек Наратның өске ботагында урын алганнар.Киптерегә

элеп куйган, онытылып калган гөмбәләрен тапканнар, ахырысы.Төлке Хәйләбай күзләрен хәйләкәр генә ялтыратып тунын кояшта киптерә.Сорыбай Бүренең хәле мөшкел, эчләрен уып ала, тәмле ризык турында уйлый. Аю Тәмлетамак сызгыра-сызгыра килеп тә җитте. Юлы умарталык аша узган .Йомран белән Тычкан Чыелдык басулардагы икмәкнең күплеге турында бер-берсен бүлдереп мактанышалар.

Аланындагы Йөзъяшәр Имәннең дусты Ныктамыр имәндә бал кортлары күп еллар яшиләр.Урманда яшәүчеләрнең бүгенге җыелуына бер дә гаҗәпләнмәделәр.

Чикерткә скрипкасын үзе утырган миләүшә чәчәкнең таҗына куйды да, беразга тынып калды.Кигәвен белән черки дә аннан үрәк алдылар.Яңгыр суалчаны да дымлырак җирне сайлап, тыңларга әзерләнде.

Түгәрәк аланда Акыл иясе Ябалак күренүгә барысы да тынып калды.Ул канатларын төзәткәләләп, зур күзлеген киеп алды да, барсы да ишетерлек итеп уфылдап куйды.

Урманның иң ихтирамлы һәм акыллы кошы җыелышны башлап җибәрде.

- Безнең алда зур эш тора: иң-иң лаек урман сылуыбызны кышкы иң матур һәм серле бәйрәмгә җибәрергә кирәк. Моның өчен патшалыгыбызда бәйге игълан ителә.Бәйрәмгә баручы турында һәр кош, җәнлек үз фикерен әйтергә тиеш. Я, кайсыгыз башлый?

Йөзьяшәр Имәннең аскы ботагына кунаклаган урман тавыкларын читтән генә күзәтүче Хәйләбай төлке сүзгә кушылды:

- Әйе, әйе, дусларым, җавапларны тизрәк бирик. Лаеклы сылуыбызны сайлыйк.Минемчә бу бәйрәмгә иң-иң лаек урман сылуы-Йөзьяшәр Имән.Карагыз, барлык җыенга килүчеләр дә аңа сыенган.Урман тавыкларын кышын да, җәен дә үзе саклый.Ничек итеп

дисезме? Җәен эсседән качалар, кышын имән тирәсендәге көрткә чумып төн уздыралар.

- Бераз гына арттырып җибәрдең, Хәйләбай.

Урман тавыклары узара шаулашып алгач,сүзләрен дәвам иттеләр.

- Без Сылу каенны бик якын күрәбез.Кыш көне аның ботакларындагы алка һәм бөреләрне ашыйбыз.Кичкә бар гаиләбез белән каен тирәсендәге тирән көрткә чумабыз.Шунда тирән коридор ясап,салкыннан сакланып төнне үткәрәбез.Кояш турырак карый башлауга Йөзьяшәр Имәнннең ботакларына да кунабыз.

- Йөзьяшәр Имәннең чикләвекләре бик күп була.

Тиен Купшы койрык шулай дип сүзгә кушылды.

- Имәннең Тукран Тукылдык ясап калдырган тишекләрендә күп кошлар оя корып бала чыгара. Без дә запас ризыкларыбызны шунда туплап калдырабыз.

Бәхәс бик озак дәвам итте.Кыска Койрык куяннар имән, усак агачларының кайрысыннан башка кышкы суыкларны җиңеп булмавын, төп ризык икәнен аңлаттылар.Миләш чыпчыклары, сызгыраклар янып торган Миләшкәйне мактадылар.Әледән әле Сылу каенкай, аның чуклы язгы киеме, тәмле суы турында бәхәс купты. Йөзьяшәр Имәннең түгәрәк аландагы урыны- барлык урманда яшәүчеләрнең җыелу урыны икәнен дә кат-кат искә төшерделәр.Урманда үсүче агач һәм куакларның барлык файдалы яклары саналып бетте.

Нәкъ шул вакытта урман аланына Чукырлар очып килде.Сүзгә кушылырга кыюлыгы җитми торган Чыршы Энәлекәйнең ботакларына кунып бәхәсне тын гына тыңладылар. Акыл иясе Ябалак бүгенге сөйләшүне төгәлләргә җыенды.Чукырларның башлыгы Акыл иясе Ябалактан сүз бирүләрен үтенде. Җыенга килүчеләр тынып калды.

-Без дә бу урманда яшәүче кошлар.Сездән аермалы буларак, кышкы суыкларда,март айларында без бала чыгарабыз.Азык табу һәркемгә кыен бу чорда, безгә чыршы белән нарат ярдәмгә килә.Аларның күркәләрендәге орлыклар белән туенабыз.Әле без генә түгел, Тиен Купшы койрыклар да азыклы була.Күркәләр генә җитмәсә,чыршы бөреләре белән дә туеналар.Зур Чуар тукран шушы күркәләрнең орлыгын үзе генә ашап калмый,песнәкләргә дә өлеш чыга.

Бәхәс кояш офык артына кереп югалганчы барды.

Көн артыннан көн үтте.Яңгырлар яуды, җилләр исте.Урмандагы тормыш дәвам итте. Акыл иясе Ябалак һаман да урманда яшәүчеләрнең фикерләрен тыңлады, яза барды.Һәрбер тереклек иясе үзенчә хаклы иде.

Көннәдән бер көнне урман моңсуланып тынып калды. Йөзьяшәр Имәннең куе яфраклары коелып бетте.Чикләвекләрен урман кошлары, тиеннәр кышка азык итеп киптерделәр, ышык урыннарга җыеп куйдылар. Сылу каенкайкайның да яфракларын шаян җилләр таратты.Бар җиһанны ак мамыкка төреп кыш килде. Ак юрган астыннан миләшнең ут сыман кып-кызыл җимешләре куренеп ала.Сайрар кошлар да җылы якларга очтылар. Үзенчә серледә, бераз моңсу да урманда.

Тирә-юньдәге тынлыкны атлар пошкырган, кыңгырау зеңгелдәгән тавышлар үзгәртеп җибәрде.Кемнәрдер күңелле тавыш белән көлешеп, сөйләшеп алалар.Кинәт кенә чукырлар, сары түш песнәкләр, урман тавыклары телгә килде. Акыл иясе Ябалак та ухылдап куйды.Урманга Кыш бабай һәм Кар кызы аяк баскан... Яңа ел бәйрәменә иң-иң лаеклы урман сылуын алырга килгәннәр.

Һәрвакыт яшел күлмәктән, зифа буйлы, моңлы җырлы, урманда яшәүчеләрнең туендыручысы, җылытучысы булган Чыршыкай лаек иде бу бәйрәмгә барырга. Кыш бабай белән Кар кызы урмандагы кошларны, җәнлекләрне, Акыл иясе Ябалакны да бәйрәмгә чакырдылар.

Ямьле язлар җиткәч, яшел күлмәкләрен Йөзьяшәр Имән дә, Сылу каенкай да, башка агач- куаклар да киде. Кышкы йокыдан уянган җәнлекләр дә түгәрәк аланга килде. Кышкы серле бәйрәм, анда чакырылган Чыршыкай турында түгәрәк аланга килеп төлке Хәйләбайның, Акыл иясе Ябалакның, Купшы койрык тиеннең хикәяләрен кат- кат тыңласалар да, кабат бәйрәмгә баручыны сайлау һаман да кабатлана. Ел саен серле Яңа ел бәйрәменә лаеклыны сайлау кабат зур бәхәс китереп чыгара.

Һәрвакыт яшел күлмәкле, зифа буйлы, моңлы, җырлы, урманда яшәүчеләрнең туендыручысы, җылытучысы булган Чыршыкайны башка бер генә агачның да алмаштыра алганы юк әлегә.

# В театр играем-речь развиваем.

**Юзыкаева Лилия Борисовна,**
*воспитатель МБДОУ №1 «Нефтяник»*

В последнее время возросли требования к качеству дошкольного образования, в том числе все больше внимания уделяется развитию речи дошкольников. К сожалению, в современном мире, все чаще живое общение детям заменяет компьютер и телевидение, и эта тенденция постоянно растет. Вследствие чего, неуклонно увеличивается количество детей, имеющих трудности в области общения, ведения диалога, как с взрослыми, так и со сверстниками.

Речь является одним из важных приобретений ребенка в дошкольном детстве. Именно приобретений, так как речь не дается человеку от рождения. Должно пройти время, чтобы ребенок начал говорить. А мы взрослые должны приложить немало усилий, чтобы речь ребенка развивалась правильно и своевременно. Это необходимое условие формирования личности ребенка. В современном образовании речь рассматривается как одна из основ воспитания и обучения детей так, как от уровня овладения связной речью зависит успешность обучения детей в школе, умение общаться с людьми и общее интеллектуальное развитие.

Театральная деятельность – это самый распространённый вид детского творчества. Одна из самых эффективных способов воздействия на детей, в котором наиболее полно и ярко проявляется принцип обучения: учить играя. Известно, что дети любят играть, их не нужно заставлять это делать. Играя, мы общаемся с детьми на их территории. Вступая в мир детства игры, мы многому можем научиться сами и научить наших детей, а театрализованная игра оказывает большое влияние на речевое развитие ребенка. Стимулирует активную речь за счет расширения словарного запаса, совершенствует артикуляционный аппарат. Ребенок усваивает богатство родного языка, его

выразительные средства. Используя выразительные средства и интонации, соответствующие характеру героев и их поступков, старается говорить четко, чтобы его все поняли. Всякую свою выдумку, впечатления из окружающей жизни ребёнку хочется выложить в живые образы и действия. Входя в образ, он играет любые роли, стараясь подражать тому, что видит и что его заинтересовало, и, получая огромное эмоциональное наслаждение.

Театрализованные игры представляют собой разыгрывание в лицах литературных произведений (сказки, рассказы, специально написанные инсценировки). Герои литературных произведений становятся действующими лицами, а их приключения- события жизни, измененные детской фантазией, сюжетом игры. Особенность театрализованных игр состоит в том, что они имеют готовый сюжет, а значит, деятельность ребенка во многом предопределена текстом произведения [3, с. 11].

Знакомство детей с театральной куклой и театрализованными играми целесообразно начинать в первой младшей группе. Радостную атмосферу малышам создает просмотр инсценировок и небольших драматизированных сказок. Затем детей постепенно знакомим с видами театров, основами актёрского мастерства.

Дошкольники очень впечатлительны, они особенно поддаются эмоциональному воздействию. Театрализованные занятия развивают и эмоциональную сферу ребенка, заставляют его сочувствовать персонажам, сопереживать разыгрываемые события. Они всегда радуют детей, способствуют не только речевому, но и умственному развитию. Исполняемая роль, произносимые реплики ставят малыша перед необходимостью ясно, четко, понятно изъясняться. Ребёнок слышит много новых слов, ему становятся понятными более сложные фразы, выражения, игровые ситуации. Все это, несомненно, способствует развитию речи, умению вести диалог и передавать свои впечатления.

Функции театрализованной деятельности:

- позволяет решать многие педагогические задачи

- она неисчерпаемый источник развития чувств, переживаний и эмоциональных открытий, способ приобщения к духовному богатству.

- участвуя в театрализованной деятельности, дети знакомятся с окружающим миром во всем его многообразии через образы, звуки, краски

- исполняя роль, особенно вступление в диалог с другими персонажами ставят ребёнка перед необходимостью ясно, четко и понятно изъясняться.

В результате целенаправленного использования театрализованных игр в организованно образовательной деятельности, а также во время свободной деятельности дети приобретают речевые навыки, на основе которых становится возможным построение связных высказываний, развивается мышление, память, воображение.

Для развития творческой активности детей в театрализованной деятельности практикуется выразительное чтение и рассказывание детей на занятиях, развлечениях, праздничных утренниках. Рассказываем детям о театральных жанрах - драматическом, музыкальном, кукольном, театре зверей, клоунаде. В процессе непосредственной образовательной деятельности, при пересказе художественного произведения используем показ настольного, пальчикового и др. театров. В играх – драматизациях, в процессе обучения, в организации сюжетно – ролевых игр решаются задачи взаимодействия театрализованной деятельности и других видов деятельности педагогического процесса. Дети привлекаются к изготовлению атрибутов, элементов декораций, костюмов, масок.

Влияние театрализованной деятельности на развитие детей неоспоримо. Это один из самых эффективных способов развития речи и проявления творческих способностей младших дошкольников. Именно в

театрализованной деятельности наиболее ярко проявляется принцип обучения: учить, играя.

Человек формируется в деятельности. Чем разнообразнее деятельность, тем разнообразнее личность.

## Список использованных источников

1.Алексеева М.М., Яшина В.И. Хрестоматия по теории и методике развития речи детей дошкольного возраста: Учебное пособие для студентов высших и средних пед. учеб. заведений. – М.: Издательский центр «Академия», 1999.

2.Кукушин, В.С. Педагогика начального образования / В.С. Кукушин, А.В. Болдырева-Вараксина. – Ростов н/Д.: Феникс, 2005. – 592 с.

3.Степанова О.А. «Методика игры с коррекционно-развивающими технологиями», Москва, «Академия, 2003.

## СЕКЦИЯ 3 «ОРГАНИЗАЦИЯ И РУКОВОДСТВО ТЕАТРАЛИЗОВАННОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬЮ ДЕТЕЙ» (ДЛЯ СТУДЕНТОВ И ПРЕПОДАВАТЕЛЕЙ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ СРЕДНЕГО ПРОФЕССИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ).

# Урман аланында

**Бубекова Ильмира Әзһәм кызы,**

**Имамутдинова Рәсимә Галиәскәр кызы**

*ҺУББ ДАМУ "Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы"ның укытучылары*

Зал урман аланы итеп бизәлгән. Тик аланда бушаган чипсы, сок каплары, пакетлар, шешәләр һәм башка чүп-чар аунап ята.

Моңсу көй астында залга Шүрәле һәм Урман иясе керә. Алар чүп-чарга карап торалар да, агач төбенә барып утыралар.

**Шүрәле.**

Әй, Урман иясе! Кара тирә-ягыңа! Болай барса, без бу урманда озак яши алмабыз. Нигә кешеләр шулай начарланды соң? Нигә табигатебезне болай мәсхәрәлиләр. Ял итәргә дип киләләр дә, чүп калдырып кайтып китәләр. Без җыештырабыз, алар пычрата. Минем хәзер теләгем дә, көчем дә калмады алар артыннан җыештырырга. Нишлибез? Нинди чаралар күрәбез? Болай булса киләсе буынга күрсәтер урманыбыз, тәмле сулы чишмәләребез, кыргый хайваннарыбыз калмас бит.

**Урман иясе.**

Мин уйлап таптым кебек. Әйдә, без ярдәмгә нәни дусларыбызны чакырабыз (кесәсеннән телефон алып, тәрбияче белән сөйләшә).

Але, бу балалар бакчасымы? Сезнең ярдәм кирәк безгә! Безнең урманда бик күңелсез вакыйга! Киләсезме? Көтәбез!

**Тәрбияче.**

Ярар, ярар. Хәзер балаларга әйтәм дә килеп җитәбез. Балалар, әйдәгез, урманга барып кайтыйк әле. Анда ниндидер күңелсез хәл булган ахыры. Бездән ярдәм сорыйлар (урман аланына килеп җитәләр).

Исәнмесез, Урман иясе, Шүрәле! Карагыз әле, урман аланын танырлык та түгел!

Балалар, әйдәгез, дусларыбызга ярдәм итик! Бу аунап яткан чүп-чарны чистартыйк. Урман иркен сулыш алсын (бергәләп чүпләрне җыялар).

**Бала.**

Апа, апа, ә бу чүпләрне кая куябыз соң?

**Тәрбияче.**

Балалар, әйдәгез, без аларга икенче тормыш бирик!

Жыелган чүпләрдән "Урман аланы" макеты һәм башка предметлар ясыйлар.

**Урман иясе.**

Рәхмәт сезгә балалар. Без сезгә ышанабыз. Зур үскәч табигатьнең сакчылары булыр дигән өметтә калабыз.

**Шүрәле.**

Менә сез балалар, үсеп җитәрсез, укып, олы кешеләр булырсыз. Тик бер вакытта да үзегез яшәгән тирәлекне пычратмагыз. Саклагыз аны. Табигать – ул тиңсез хәзинә. Ул кешеләр ярдәменә, сезнең ярдәмгә мохтаҗ. Сез аны ничек сакласагыз – ул сезгә җавап итеп мул уңышын бирер. Сезгә дә, сездән соң киләчәк буыннарга да табигый байлыклар җитәрлек булсын.

**Урман иясе.**

Килегез урманга балалар,
Анда бар аланнар.
Аланда- хуш исле чәчәкләр,
Тимәгез,өзмәгез аларны,
Матурлык дөньясы бит алар.

Сузып-сузып сайрый кошчык,
Канатын кага-кага.
Оя ясыйк, җимлек элик,
Ярдәм итик аларга.
Кыю, җитез җәнлекләрнең
Урман-туган йортлары.
Рәнҗетмик, кыерсытмыйк,
Хөрмәт итик аларны!
Агачларны сындырмагыз,
Кош оясын ватмагыз.
Суларны да пычратмагыз,
Пыяла, чүп атмагыз.
Эссе чакта коры чакта
Урманда ут якмагыз.
Табигать ул-безнең анабыз,
Табигатьне саклагыз!
Учак яксак урманнарда,
Сүндерик без кисәвен
Һәм җыярга онытмыйк
Чүп - чар, кәгазь кисәген.
Без табигать - балалары,
Кояш белән янабыз
Бездән һәрчак риза булсын
Шул табигать - анабыз.
(Балалар саубуллашып, бакчага кайтып китәләр).

**Чему учит студенческий театр?**

**Титова Неля Музафаровна**,
*преподаватель русского языка и литературы*
*ГАПОУ «Мензелинский педагогический колледж*
*имени Мусы Джалиля»*

Студенческий театр — один из видов самодеятельного народного театра. Возможно, у него несколько специфический репертуар — он берет пьесы, которые ближе его аудитории. Возможно, у него несколько специфический зритель — в зале в основном сидят студенты, однокашники тех, кто на сцене, и, следовательно, они лучше понимают и лучше чувствуют друг друга. Возможно, наконец, у него несколько иной состав актеров — это все сверстники, между ними дистанция в два-три курса, не более. Однако, встав на этот путь определения сути студенческого театра, скоро замечаешь, что накопление этих «возможно» неизбежно перерастает в иное качество. Зритель особый, репертуар особый, актеры особые — а что же, в конце концов, еще составляет театр? Нет, подвести студенческий театр под обыденное понятие «самодеятельный театр» вряд ли удастся. Что-то иное, что-то иное... Но что? Очень для всех нас важное, ценное, со своей культурой.

Студенческий театр то умирал, то возрождалась вновь, порой из полузабытья, порой из пепла, как фантастическая птица Феникс, дух которой никогда не умирал. Театральная студия, где постигается актерская грамота, является не только начальной ступенью театрального образования, но и новой, эффективной формой общего и эстетического развития студентов. Необходимым условием обучения является создание оптимальных педагогических условий для формирования личности будущего артиста-любителя. Театральные студии предназначены обучать и воспитывать способных к художественному творчеству студентов. Во всем комплексе учебно-воспитательной работы основным направлением усилий

руководителя театральной студии является развитие у ученика стремления к познанию, высокой требовательности к своей работе, активного творческого участия в создании художественного результата. На протяжении всего обучения абсолютная ценность самостоятельности, самобытности, своеобразия личного подхода к решению творческих задач требует обостренного и чуткого внимания педагога к поискам, находкам и предложениям учеников.

Основной функцией театра была и остается развлекательная. Отсюда следует, что театр издревле удовлетворял естественную потребность человека в зрелищах.

Театр родом из жизни, а значит, каждая театральная постановка всегда рассказывает нам о нас самих.

Вторая важнейшая роль театра в жизни человека – развивающая. Театральная практика – популярный способ саморазвития, а также полезный активный отдых и просто приятное времяпрепровождение. Актерская практика развивает в человеке:

- эстетическое чувство;
- чувство внутренней свободы;
- чувство ритма и владение телом;
- умение сопереживать и ставить себя на место другого человека;
- умение грамотно излагать и доносить свою мысль, а также выражать ее без помощи слов;
- умение разбираться в людях и жизненных ситуациях;
- любовь к литературе и способность к осмысленному полезному чтению.

В воспитании студентов театр имеет большое значение. Современная педагогика рассматривает возможности театра в качестве реального средства художественного воспитания обучающихся. Театр во все

времена был школой талантливого зрителя. Неотъемлемой частью и урока театра, и факультатива, и театрализации как средства развития личности ребенка стал компонент театральной культуры, который заключается в знакомстве студентов с театром как видом искусства, в освоении элементов актерского мастерства и постановке спектаклей, в которых играют ребята. Театральное образование и направлено на воспитание основ зрительской культуры, развитие навыков театрально-исполнительской деятельности, накопление учащимися знаний об искусстве театра.

Казалось бы, роль театра в воспитании школьников и студентов очевидна, однако не для всех. Поясню. Популярность студенческих самодеятельных театров и театральных кружков обуславливается тремя главными факторами:

1. Возможность игрового обучения. Основой театра является мировая классическая литература, которая так сложно усваивается детьми через чтение, и так просто – через действие на сцене.

 Постановка спектакля – это коллективный труд, постоянная работа с партнером, умение брать на себя ответственность за других людей и за общее дело, доброжелательное отношение друг к другу. Станиславский в своих беседах с молодежью основной предпосылкой для роста коллектива и каждой отдельной личности в коллективе утверждал принцип доброжелательства. Он говорил: «Если вы вообще не обладаете доброжелательством к людям, работайте над ним. Выпроваживайте за двери— зависть, сомнения, неуверенность, страх — и открывайте, распахивайте двери для радости».

2. Каждый актер должен непрерывно развиваться и совершенствоваться, только так можно раскрыть свой талант, отточить навыки и научиться чему-то новому. Неотъемлемая часть актерского мастерства – речь, которая помогает передавать эмоции, служит связующим звеном

между актером и зрителем. Театр развивает в человеке такие качества, как трудолюбие, терпение, дисциплинированность, творческие способности. Занимаясь в театральных кружках и студиях, студенты становятся уверенными, стремятся вести беседу грамотно, овладевают сценической речью, многие студенты преодолевают сложности в коммуникации «языковой барьер».

3. Театр способен увлечь студента, стать его хобби и уберечь от попадания под пагубное влияние дурных привычек и неблагополучных компаний.

Кроме того, роль театра в формировании личности обучающихся подтверждена психологами как верное средство для преодоления неуверенности в себе, развития важных коммуникативных навыков и формирования здоровой самооценки у детей всех возрастов.

В театральных студиях ребята учатся:

- снимать зажимы и умение раскрепощаться. Смотреть прямо на свои страхи и избавляться от них
- работать не только на сцене, но и на камеру
- развивать мимику своего лица
- работать со своим спектром эмоциональных состояния
- импровизировать
- ставить свой голос и делать его сильным и уверенным
- развивать внимание, память и воображение.
- практиковать правильную технику речи и дыхание, ставить голос и дикцию.
- развивать собранность и уверенность.
- погружаться в себя и анализировать свои привычки.
- работать с текстом.

- взаимодействовать с партнером и пространством — учиться чувствовать мир вокруг себя.
- прокачивать мышечную выносливость, координацию и ритмику.

Хороший актёр - убедителен. Одно из важнейших качеств актёра - внимательность. К себе и ко всему вокруг. В подтверждение приведу цитату русского драматического актера Михаила Александровича Чехова "Если хотите заниматься творчеством, сначала займитесь жизнью".

**Список использованной литературы:**


1. https://partacademy.ru/acting_beginner
2. http://dspace.rsu.edu.ru/xmlui/bitstream/handle/123456789/604/kirillov_studencheskii_teatr_kak_komponent_sistemi_vishego_uchebnogo_zavedenia.pdf?sequence=1
3. https://cyberleninka.ru/article/n/vospitanie-studentov-v-vuze-sredstvami-teatra